МӘҢГЕ ХӘТЕРДӘ
Ветераннарның батырлыкларын онытырга хакыбыз юк
> 3–4

АВЫЛ ИМАМЫ
«ВТ» укучыларының саладагы дин әһелләре турында язмалары
> 5

ИХЛАС НАИЛ
Хезмәттәшебез гомер бәйрәмен нинди уйлар белән каршылый?
> 6

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
«Кешене бернинди үлчәмнәр белән тулысынча бәяләп тә, аңлап та булмый»
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 64 (28837) | Шимбә | 7 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Бөек Җиңү көне ил тарихында аерым урын алып тора. Тик илдә җитәкчелек һәм җитәкчелеккә бәйле рәвештә идеология үзгәреп тору нәтиҗәсендә аның әһәмияте, абруе бер артты, бер кимеде.

«Татар-информ»

Һәйкәл
БӘЙРӘМ АЛДЫННАН УЙЛАНУЛАР

1945 елның 8 маенда СССР Югары Советы карары нигезендә 9 Май ял көне дип игълан ителгән иде. Әмма 1947 елдан 1965 елга хәтле Җиңү көнен зурлап билгеләп үтү тукталып торган. Мондый «озын тәнәфес»нең сәбәбен төрлечә аңлаталар. Беренчедән, сугыштан соң бөтен халык илне торгызу уе белән янганда, бәйрәм кайгысы булмаган, диләр. Тагын бер фараз буенча, сугыштан соң маршал Жуковның дәрәҗәсе бик күтәрелгән һәм бу Сталинның абруена сугар дип шикләнгәннәр, имеш. Георгий Жуковны юкка гына «маршал победы» дип атамаганнар бит.

Хакимияткә Хрущев килгәч, аңа, 9 Майны ял көне итүне сорап, халыктан гозерләр ява башлый. Тик ул халык сүзенә колак салмый, чөнки хакимлеккә килүгә, иң беренче эш итеп, Сталинның шәхес культын фаш итә. Ә халык Бөек Ватан сугышында җиңүне Сталин исеме белән бәйли. Совет солдатлары юкка гына «За Родину, за Сталина!» дип утка кермәгән бит! Кыскасы, хакимлеккә Брежнев килгәнче 9 Май көне зурлап бәйрәм ителми. Леонид Ильич үзе дә хәрәкәттәге армиядә була һәм сугышны генерал-майор дәрәҗәсендә тәмамлый. Мондый шәхеснең Җиңү көненә мөнәсәбәтен аңларга була, 9 Май янә ял көне дип игълан ителә.

Нәкъ шул елларда Татарстан авылларында сугышта һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл-обелисклар калкып чыга башлады. Ул елларны мин мәктәптә укый идем. Һәйкәлләр салуны, мөгаен, Бөек Җиңүнең 20 еллыгына туры китерергә теләгәннәрдер. Зур эшләрне юбилейларга бәйләп башкару – бездә элек-электән килгән матур бер гадәт инде. Монысын сүз уңаеннан гына яздым, ә менә һәйкәлләрне халык үзе ясавына аерым тукталасы килә. Аларны сугыш ветераннары үзләре калкытты. Минем туган авылым Субаш Атыда, мәсәлән, һәйкәлне сугышта бер кулын имгәтеп кайткан Һидият абый салды. Ул мич чыгаручы иде. Күрәсең, үз эшенең остасы булганга, һәйкәл салуны аңа йөкләгәннәрдер. Бу хакта мәрхүм әтием Солтан, шулай ук сугыш ветераны, шигырь дә язган иде. Шигырьдә мондый юллар да бар:

Скульпторы гади ташчы аның,
Бер кул белән кайтып сугыштан,
Кире калкыткан менә бу һәйкәлне
Гади таштан, гади цементтан.

Әйе, бик гади иде ул һәйкәл. Әмма анда бәйсезлек өчен утны-суны кичкән авылдашларымның күңел җылысы саклана кебек. Һәлак булганнарның исемлеген язганда әтием дә, сугышта уң кулы гарипләнгән, шуңа күрә сулагайга әйләнгән Гыйльмиҗан да, самолетта янып гарипләнгән укчы-радист Әнәс абый да исемлектәге һәр авылдашлары турында озаклап-озаклап сөйләшәләр иде. Җиңү көне якынлашкан саен, шул сөйләшүләр искә төшә. Әле һәйкәл ачылганчы ук аның тирәсенә халык килә иде. Күз яшьләрен көчкә тыеп, исемлекне барлыйлар, һәлак булганнар турында истәлекләр уртаклашалар иде алар.

Безнең артык зур булмаган Субаш Аты авылыннан гына да сугышта 150 кеше һәлак булган, бу – йорт саен бер үлем дигән сүз. Әйтүләренчә, әлеге исемлек тулы түгел әле. Баштарак әсирлектә булганнарның, хәбәрсез югалганнарның исемнәрен язу тыелган. Еллар узган саен, исемлек тулылана бара, һәйкәлләрнең рәвеш-кыяфәтләре дә үзгәрә, кирпечләрне мәрмәр ташлар алыштыра. Аларга сугыштан исән-сау кайтканнарның, тыл батырларының исемнәрен дә яза башладылар. Халык хәтере әнә шулай мәрмәр ташларга да уела башлады. Һәйкәлләр – хәтер яңарту урыны, алар – тарихның шаһитлары.

Ирексездән, бүген дөньяда барган күңелсез вакыйгалар күз алдына килә. Европаның кайбер илләрендә әлеге «тарихи шаһит»ларны юк итү бара: һәйкәл-обелискларны вата-җимерәләр. Бөек Ватан сугышын һәм аның нәтиҗәләрен бөтенләй башкача бәяли башладылар. Хәер, бу сәясәттә әллә ни яңалык юк. Икенче Бөтендөнья сугышында безнең союзник саналган Америка белән ике арадагы мөнәсәбәтләр 1946 елда ук үзгәрде: СССР белән АКШ арасында салкын сугыш башланды һәм аның хәзерге көнгә хәтле тынганы да юк. Мәгълүмати сугыш киң колач алды, ишетүемчә, әлеге сугыш өчен Пентагон тәүлегенә 1,5 млн доллар акча бирә икән. Мәгълүмат кыры ялган белән тулды. Пычрак тиз йога бит ул, әмма аннан арыну озак.

Безнең күз алдыбызда фашизмның бөтен сыйфатлары шәйләнә, мин үзем бер генә халыкны да гаепләмим, Ходай Тәгалә һәр кешене тигез яраткан, дим. Хикмәт бары тик җәмгыятьтә нинди идеология хөкем сөрүендә.

Авылларда еш булам мин. Халык Украинадагы хәлләр белән бик кызыксына. Кайчандыр союздаш булган илләрдә тарихи һәйкәлләрне җимерү авыл кешесенең башына сыймый. Үзебезчә, авылча итеп: «Ничек куллары корымый икән?» – диләр. Зур сәясәт – алар өчен ят нәрсә, бөтен теләкләре «Сугышлар гына булмасын!» дигән өч сүздән тора. Безнең авылда сугышта катнашканнарның берсе дә исән түгел инде. Соңгы ветеран минем әти иде.

...Һәйкәл янына быел да илнең иминлеге өчен көрәштә һәлак булганнарның, яу кырыннан исән-сау кайтып, сугыш яраларыннан бик иртә дөнья куйганнарның балалары, оныклары, туганнары киләр. Аларның саны инде ишле булмас. Әмма хәтер яшәр, әгәр һәр буын аны яңартып торса, диюем.

Соңгы сүз итеп: «Инде яңа һәйкәлләр генә калкып чыкмасын!» – диясе килә.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ҖИҢҮ КӨНЕ БЕЛӘН!



Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгы уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВ МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Кадерле фронтовиклар һәм тыл хезмәтчәннәре!

Сезне бөтен халык бәйрәме – Җиңү көне уңаеннан чын йөрәктән тәбрик итәм!

77 ел элек күпмилләтле совет халкы Бөек Ватан сугышында кешелекнең мәрхәмәтсез дошманы – фашизмны тар-мар итте. 1945 елның 9 май кичендә тарихтагы иң вәхшәтле, иң канкойгыч, кешелексез сугышның тәмамлануын, бик озак көтелгән тынычлык урнашуын белдереп, Ватаныбызның күгендә Җиңү салюты яңгырады. Моңа кадәр миллионлаган кешенең бер булып шул дәрәҗәдә зур шатлык хисләре кичергәне, Туган җирнең бөеклеген һәм хөрлеген саклап калган кыю сугышчыларга ихлас күңелдән дан җырлаганы булдымы икән?!

Бөек Җиңү ул – данлы Ватаныбыз тарихының иң күренекле вакыйгасы, халыкның корычтай нык рухы, каһарманлыгы күрсәткече, гаделлек һәм хаклыкның явызлык көчләреннән һәм золымнан һәрчак өстен чыгуына ачык бер мисал. Илебезнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән тыгыз бәйләнештәге Җиңү көне сугыштан соңгы буыннар хәтеренә тирән уелды, күпсанлы һәйкәлләрдә, шәһәрләр, авыллар һәм урамнар атамаларында, музейлар һәм панорамалар экспозицияләрендә мәңгеләштерелде.

Икенче бөтендөнья сугышы – кешелек тарихында иң зур фаҗига, ул бик күп дәүләтләргә һәм халыкларга исәпсез-хисапсыз бәлаләр китерде. Әмма иң зур югалтулар, кешеләрнең күпләп вафат булуы, шәһәрләрнең, авылларның җимерелүе, юкка чыгуы безнең ил язмышына төште.

Бүген без, шөһрәтле Җиңү көнен бәйрәм иткәндә, беренче нәүбәттә, Туган җиребезне һәм бөтен дөньяны нацистлардан каһарманнарча саклап, сугышның коточкыч тегерменендә һәлак булган, дәһшәтле бомбага тотулардан, ядрәләрдән гомере өзелгән, концлагерьларда юк ителгән, камалыштагы Ленинградта ачлыктан үлгән һәркемнең рухы алдында баш иябез. Дошман басып алган җирләрдә аяусыз изүдән җәфа чиккән, туган йортын ташлап, чит җирләргә күченеп китәргә мәҗбүр булган кешеләрне искә төшерәбез, сугыш чоры балаларына һәм яраланып кайткан солдатларга олы хөрмәтебезне белдерәбез.

Татарстаннан фронтка киткән җиде йөз меңнән артык кеше, кулына корал тотып, Ватан азатлыгын яклап сугышты, шуларның яртысыннан артыгы яу кырында мәңгелеккә ятып калды. Кызганыч, аларның барысына да югары бүләкләр тапшырылмады, әмма шулай да бу каһарманнарның һәрберсе Җиңүгә үзеннән саллы өлеш кертте. Муса Җәлил, Михаил Девятаев, Мәгубә Сыртланова, Петр Гаврилов, Гани Сафиуллин, Николай Столяров, Фәрит Фәтхуллин, Борис Кузнецов, Гази Заһитов, Михаил Симонов һәм башка бик күпләрнең исеме Бөек Җиңү елъязмасына алтын хәрефләр белән язылды.

Завод цехларында дошманга каршы дәһшәтле корал койган һәм авыр сугыш алып барырга мәҗбүр булган илне азык-төлек белән тәэмин итү өчен армый-талмый эшләгән тыл хезмәтчәннәре чиксез олылауга лаек. Татарстанның башкаласы Казанга «Хезмәт батырлыгы шәһәре» исеме бирелү, һичшиксез, аларның фидакарьлеген тану һәм зур хөрмәт билгесе буларак кабул ителә.

Четерекле хәзерге заманда җиңүчеләр буыны васыять итеп калдырган идеалларга тугрылык саклау гаять мөһим. Бүген татарстанлылар – ветераннарның дәвамчылары – күпмилләтле Ватаныбызның мәнфәгатьләрен яклап, шул исәптән Украинадагы махсус хәрби операциядә дә үзләренең хәрби бурычын намус белән үти. Аларның һәрберсе тарих безгә йөкләгән җаваплылыкның ни дәрәҗәдә зур булуын бик яхшы аңлый.

Бөек Ватан сугышының сабаклары нацистларның «көрән» идеологиясен тараткан, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен санга сукмаган, халыклар арасында дошманлык орлыклары чәчкән һәркемнең, алар күпме генә «ак кием»нәргә төренеп маташмасын, җәзага тартылачагына шик калдырмый. Җиңү китергән 1945 елдагы кебек үк тарихта бердәнбер гадел чишелеш табылыр, нацизм кебек абсолют явызлыкка хәзерге дөньяда урын булмавы тагын бер кат расланыр дип ышанам.

Сугыш һәм хезмәт ветераннарына чын күңелдән сәламәтлек һәм иминлек, ә халкыбызның сугышчан һәм хезмәт даны варисларына илнең оборона куәтен, икътисади һәм мәдәни үсешен ныгытуда зур уңышлар, тынычлык, бәхет һәм күңел күтәренкелеге телим!

Җиңү көне котлы булсын, кадерле дуслар! Бәйрәм белән!

Хәерле юл!

Штраф белән генә чикләнмиләр

Май ае – җәяүлеләр өчен аеруча куркыныч чор. Юл сагында торучылар шулай дип кисәтә. Татарстанның ЮХИДИ идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, соңгы биш елда республика юлларында нәкъ менә язның соңгы аенда җәяүлеләрне бәрдерү очраклары арта икән.

Быелның беренче дүрт аенда Татарстанда 21 җәяүленең гомере өзелгән. Аларның күбесе юлны тиешле урыннан чыкмаган булган. Ел башыннан бирле Татарстанда җәяүлеләр үзләре 20 мең тапкыр юлда йөрү кагыйдәсен бозган. Бу хакта юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Татарстанның Хөкүмәт комиссиясе утырышында Россиянең ЮХИДИ Баш идарәсе башлыгы урынбасары, моңа кадәр республика инспекциясен җитәкләгән Ленар Габдрахманов хәбәр итте. «Җәяүлеләрне бәрдерү очракларын киметү өчен, республикада планлы рәвештә тротуарлар төзелә, юллар яктыртыла. Агымдагы елда 12 чакрым озынлыктагы 13 юл участогында тротуарлар төзеләчәк, 81 чакрым озынлыктагы 49 юл участогына яктырту җайланмалары куелачак», – диде бу атнада яңа вазыйфага билгеләнгән Ленар Габдрахманов.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Быел республиканың төбәк юлларында теркәлгән һәлакәтләр саны 20 очракка кимегән. Һәлак булганнар – 4 кешегә, имгәнгәннәр, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 45 кешегә азрак булган. Федераль юлларда хәлләр мөшкелрәк. Үлем-китем очракларының яртысы нәкъ менә зур юлларда теркәлгән. Быел Татарстанда автобуслар катнашындагы юл һәлакәтләре саны да кимегән. Саннар теленә күчсәк, ел башыннан бирле республика юлларында, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 11 очракка азрак теркәлгән.

Җәйге яллар чоры җитүгә генә түгел, мәгълүм вакыйгаларга бәйле рәвештә республикада транспорт ташкыны зураерга мөмкин. «Шуңа күрә моңа алдан әзерләнергә кирәк. Билгеле бер район территориясендә транспорт хәрәкәте көчәйгән шартларда транспорт куркынычсызлыгын тиешле дәрәҗәдә тәэмин итәргә кирәк», – диде Ленар Габдрахманов.

Яшерен-батырын түгел, елның-елында юлларда исерекләр гаебе белән дә дистәләрчә юл һәлакәте теркәлә. Быел дүрт айда гына да рульдәге сәрхушләр 27 юл һәлакәте китереп чыгарган. Аларда бер кеше үлгән, 38 кеше имгәнгән.

Ахыры 2 нче биттә >

Хәтер

ЯУ КЫРЫНДА – ТАТАРСТАННЫҢ ӨЛЕШЕ



ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Геростратны онытыргамы,
яки Шапокляк кортка формуласы

Елларда Григорий Горинның «Геростратны онытырга!» («Забыть Герострата!») дигән пьесасын укып чыктым. Тәэсирле әсәр. Хәтсездән язылган булса да, бүген дә бик актуаль. Геростратның кемлеген күбебез белә булыр. Пьесаның үзәгендә – моннан егерме дүрт гасыр элек Борынгы Грециядә кылынган җинаять. Кулыннан юньләп берни дә килмәгән мин-минлекле вак сәүдәгәр (чынлыкта терлекче булган, диләр) Герострат, тарихка мәңгегә кереп калу нияте белән, дөньяның җиде могҗизасының берсе саналган Артемида гыйбадәтханәсенә (храмына) ут төртә, аны яндыра. Җинаятьчене кулга алганнан соң, андый хәл бүтән кабатланмасыннан да бигрәк, затсызның теләге тормышка ашмасын дип, шәһәр башлыгы «Геростратны онытырга!» дигән указ чыгара…

Явызлыкны оныту дөресме? Кешелек оныттымы ут төртүчене? Әсәрдә үк әйтелгәнчә, оныту аны гафу итүгә тиң гамәл булыр иде. Икенче яктан алганда, йөз, йөз илле ел буе иң оста төзүчеләр төзегән могҗизаны, бөек сәнгать әсәрен бер төндә юкка чыгарган адәм актыгы тарихка керергә, анда калырга аз гына да лаек түгел кебек. Нәкъ менә адәм актыгы, җинаятьче, юньсез кеше булганы өчен.

Тик менә чал тарихка карасак, без анда төрледән-төрле җинаятьче-залимнәрнең, сугыш чукмарларының, меңнәрнең җанын кыйган яулап алучыларның исемнәрен, аларның тулы җыелмасын күрәбез. Ягъни Геростратны да, аңардан соң килгән дистәләгән башка «ут төртүчеләр»не дә кешелек онытмады. Дөресме болай эшләү? Кистереп әйтү кыен да хәтта. Онытмау бары бер очракта гына аклана кебек. Үткәннәрдән сабак, гыйбрәт алып яшәгәндә, әшәкелекләрне кабатламас булганда, андыйга юл куймаганда. Бу шарт, ни гаҗәп, үтәлми. Кешелекнең коллектив хәтере ни өчендер кыска, акылы башкача эшли. Кешелек, зурдан алганда, акылсыз. Акыллы затлары, фикер ияләре очраштыргалаган тәкъдирдә дә акылсыз ул. Мең, миллион юләрнең күмәк акылы «Тарихның төп сабагы – аннан сабак ала белмәү», – дип язган Бернард Шоу кебекләр акылына тора микән? Юктыр! Җиргә бүксә кайгысын гына кайгыртырга килгән күпчелек, кызганыч ки, тарихи, фәлсәфи категорияләр белән уйлый белми. Белсә, кешелек тарихы, адәми зат үзенә, үзе кебекләргә китереп торган фаҗигаләр, җинаятьләр, барыннан да бигрәк сугышлар тарихы булмас иде. Кешелек ничәмә-ничә тапкыр басылган бер үк тырмага кабат-кабат китереп басмас иде. Кыйналганын онытып, инде фәләненче катка кәбестә бакчасына кергән, яңадан сырты каезланачак кәҗә ролендә яшәмәс иде. Бит кайсы гына гасырны алма, карама, аның – үз Геростратлары.

Икенче яктан алганда, кешеләр антик чорда ук Артемида гыйбадәтханәсе кебек могҗизалар тудыра алган. Тик биредә дә каршылыкка юлыгабыз. Гаҗәп түгелме, сәләтле архитекторлар җитәкчелегендә гасыр буе төзелгән бөек храм авторларының, төзүчеләренең берсен дә белмибез. Ә аңа ут төртеп, бер төндә юк итүчене беләбез. Монысы да – кешелекне һич бизәми торган сансызлык һәм гаделсезлек. «Яхшылык кылып, дан алу кыен», – дип сөйләнгән Шапокляк карчык искә төшә. Ниндидер хикмәт аркасында император була алган философ Марк Аврелий (чал тарихта бердәнбер очрак) кемнең генә исендә дә, кемнәр генә аның хезмәтләрен укыган? Бик-бик азлар. Ә менә ут һәм кылыч белән ярты дөньяны яулаган, кан елгалары агызган Александр Македонский, Чыңгыз хан, Аксак Тимер, Наполеон Бонапарт ишеләрне һәр мәктәп баласы белә. Белү гаеп саналмаганда да аларның җимерүче, җан кыючы икәнлеге мең дә бер кат ассызыкланырга, ул затларга мәңге юылмаслык кара тамга тагылырга кирәктер дә бит. Әмма тарих дәреслекләрендә андый нәрсә күзәтелми.

Геростратлар каян чыга соң? Җирдә яшәгән һәркемнең дә диярлек уңышлы да, данлы да буласы килә. Кемдер уңышны акчада, байлыкта күрә, шуңа табына. Кемнәрдер, мәшһүр сәнгать әсәре тудырып, исемен мәңгеләштерә. Акыл ияләре акыллы сүзләре белән, Гомерлар үз «Илиада» һәм «Одиссея»лары белән тарихта, буыннар хәтерендә кала. Хакимияткә ирешкәннәр, власть пирамидасының башына менгәннәрнең дә бөек буласы, дөнья тарихында булмаса, ил тарихында урын аласы килә. Андыйлар арасында, әйткәнебезчә, Герострат юлын сайлаганнар да хәтсез. Нәкъ шундый золымчыларны – безнең цивилизациянең төп фаҗигаләре сәбәпчеләрен тудырмый кала, тыя алганда гына кешелекне кешелек дип атап булыр иде кебек.

Ихтимал, Герострат кешелек тарихында беренчеләрдән булып әшәке данның да дан икәнен аңлаган, бернәрсәгә сәләтең булмаган килеш тә елъязмаларга, миллионнарның теленә эләгү мөмкинлегенә төшенгән зат булгандыр. Бүген андый затсыз юлны күпләр белә булыр. Бүгенге дөньябыз шуңа да төрледән-төрле кечкенә Геростратлар белән тулы. Гауга-скандаллар оештырып, шуннан очколар туплаучы, шул юл белән үзләрен даими искә төшереп торучы шоу-бизнес вәкилләре әллә вак Геростратлар түгелме? Ә кырыкмаса-кырык видеоблогерлар? Әлбәттә, алар тарихта калмаячак. Тик миллионнар аларны белә, аларны сөйли, алар белән кызыксына. Инде оныттылар дигәндә, андыйлар яңа гауга яисә яңа мөгез китереп чыгара. Интернет, сары мәгълүмат чаралары исән булганда, Шапокляк кортка формуласын үз иткәннәр һәрчак исән. Алар гавамның бернинди кысаларга да сыймаган сыйфатын – начар, хәтта шакшы гамәлләрне шәбрәк «йотып» баруын файдалана, ул гамәлләрнең аны хәтта яхшырак та рекламалавын белеп эш итә. Ә кайбер сәясәтчеләр? Шул ук Жириновский соңгы өч дистә елда Россия сәяси Геростратларының берсе түгел идеме? Нәкъ үзе иде. Җәмгыятькә, илгә бер тиенлек файдасыз көе, көн туса, Думада яңа мөгез чыгарып, спектакль куеп, гауга оештырып, хатын-кызларны шунда ук чәченнән сөйрәгән затның популярлыгын башкача ничек аңлатырга?..

Ут төртүчеләрне, тарихи Геростратларны, әшәкелек белән исем казанганнарны оныту, әлбәттә инде, дөрес түгел. Хәер, андыйлар мәҗбүр иткәндә, указ чыгарганда, теләгәндә дә онытылмый. Шул җәһәттән Горин пьесасында булмаган, тик аңа кагылган мәзәк барлыгы мәгълүм. Указның үтәлешен тикшерүчеләр, грекларны төнлә уятып: «Син кемне онытырга тиеш әле?» – дигән сорауга аларның һәрберсе, һич тә икеләнмичә: «Геростратны!» – дип җавап кайтара торган булган, имеш… Бәс онытмыйбыз икән, тарихта махсус кара исемлек булдырасы, андагы һәр антигеройны бары ләгънәт укып искә аласы, яңалары тумасын өчен, мөмкин булганны эшләп торасыдыр.

«СЕЗ – БИК БӘХЕТЛЕ КЕШЕЛӘР»

Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Казанның милли тикшеренү техник көллиятендә белем алучы студентлар белән очрашты. «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) илкүләм чемпионаты җиңүчеләре һәм финалчылары парламент башлыгы белән республика икътисады, эшче һөнәрләрнең абруе турында фикер алышты.

tatarstan.ru

«Республиканың күптармаклы икътисады күпсанлы эшче куллар таләп итә. Шуңа да бездә югары квалификацияле белгечләр әзерләү мәсьәләсенә зур игътибар бирелә. Һөнәри белем бирү процессы мәктәп диварларыннан чыкканчы ук башлана. Бу мәсьәләдә WorldSkills кебек һөнәри осталыкны сыный торган чемпионатлар да зур роль уйный», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Билгеле, очрашуда икътисад, һөнәри үсеш турында гына сөйләшмәделәр. Студентлар парламент башлыгының гап-гади авылдан Дәүләт Советына кадәр үткән юлы, уңыш серләре белән дә кызыксынды. Беренче курс студенты Алмаз Хәмәтшинның шундый эчтәлектәге соравына җавап биреп, Дәүләт Советы Рәисе башта: «Минем кебек «Мөхәммәтшин» булырга аз гына калган икән сиңа да», – дип шаяртты. «Иң беренче чиратта, кешеләрне яратырга кирәк, Алмаз. Аларның ышанычын башкача яулау мөмкин түгел. Мин ирешкән уңышларда гаиләдә, мәктәптә алган тәрбия дә зур роль уйнады. Сезгә исә мин ялкауланмаска, белем алудан туктамаска, тәҗрибә тупларга киңәш итәм. Сез – бик бәхетле кешеләр. Мөмкинлекләрегез гаять күп, кулдан ычкындырмаска гына кирәк. Алмаз, укып бетереп, диплом алгач килерсең, берәр урын карарбыз без сиңа», – дип өстәде Мөхәммәтшин, егет-кызларга бары уңышлар теләп.

Алмаз үзенең иҗат белән кызыксынуын да сөйләде. Парламент йортында Габдулла Тукайның «Сөбханалла, сөбханалла» шигыре дә яңгырады. Фәрит Мөхәммәтшин исә яшьләргә һөнәри яктан үсешкә генә игътибар итеп, рухи кыйммәтләр турында да онытмаска киңәш бирде.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

САН

«Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) илкүләм чемпионатының финал алдыннан сайлап алу ярышларында Татарстан җыелма командасы барлыгы 157 компетенциядә көч сынашып, 64 медаль (20 алтын, 18 көмеш һәм 26 бронза) яулады һәм югары профессионализм өчен 45 медальонга ия булды. Чемпионатның финалы 8–12 сентябрьдә Саранск шәһәрендә узачак.

ИСЕМЕН БОЗЫП, КЕМ КУЙГАН?

ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ ЭЛМӘ ТАКТАЛАРДАГЫ ХАТАЛАРНЫ ХАЛЫК ТИКШЕРӘ

Хата тапкан өчен бүләк бирәләр. Бары тик торган-йөргән җиреңдә игътибарлырак булырга гына кирәк. Хәер, хаталар булдырмас өчен, бу сыйфат башкаларга да ярап куяр иде.

Икенче ел рәттән Татарстанда татар телендәге элмә такталар эчтәлегендә төгәллек булдыруга бәйле конкурс оештырыла. Активлык күрсәткән 10 кешене кыйммәтле бүләкләр көтә. Әлеге бәйге Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе теләктәшлеге белән уздырыла.

Бәйгедә теләсә кем катнаша ала. Игътибарлы, татар теленә битараф булмавың, язуда хаталар таба белүең җитә. Моңа өстәп, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында теркәлгән яисә «Халык контроле» мобиль кушымтасының кулланучысы булу да шарт. Мөрәҗәгатьләрне порталның махсус бүлегенә юллыйсы.

– Узган ел 10 җиңүченең өчесен – «Айфон», калганнарын башка төр смартфон белән бүләкләдек, Рәхмәт хатлары бирдек. Быел әлеге бәйге 1 мартта башланды. 1613 мөрәҗәгать килеп иреште инде, – диде Татарстанның кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская. – Мөрәҗәгатьләр саны соңгы ике елда артты да. 2020 елда боларның саны 35 булса, 2021 елда 3 меңнән артып китте. Бәйге игълан итүебез дә моңа сәбәпче.

«Халык контроле»нә Казан, Чистай, Чаллы, Яшел Үзән, Питрәч, Бөгелмә, Лаеш, Алексеевск, Тукай, Әлмәт, Биектау, Югары Ослан һәм Зәй районнарыннан мөрәҗәгатьләр аеруча күп килә икән.

– Башка районнардан бер мөрәҗәгать тә булмавы аларда хаталар юк дигән сүз түгел әле, – диде бу җәһәттән Сәрия Сабурская.

Хата табу – бер хәл, аларны вакытында төзәтү – башка мәсьәлә. Моңа теләк тә кирәк әле. Сәрия Сабурская әйтүенчә, республикада татар теленә тәрҗемә ителмәгән язулар, элмә такталардагы хаталар вакытында төзәтелми.

– Башкарма комитет һәм районнарда безнең мөрәҗәгатьне озакка сузып карыйлар, бу эш вакытында башкарылмый. Сәбәбен акча җитмәү белән аңлаталар. Бюджеттан акча бирелсә, шул вакытта гына төзәтү эшләренә алыналар, – диде ул.

«Халык контроле»нә килгән мөрәҗәгатьләрдә хаталарның барлык төрләрен дә очратырга була: хәреф төшеп калган, дөрес язылмаган, тыныш билгесе куелмаган һ.б.

– Әлеге төр хаталарны ике төркемгә бүлеп карарга була. Бердән, бу – иң гади игътибарсызлык, ваемсызлык хатасы. Мисал итеп, татар телендә кулланыла торган хәрефләрнең язылышына бәйле хаталарны китерергә мөмкин, – дип аңлатты филология фәннәре кандидаты Рифат Мирхаев. – Икенче төре – грамматик, сүзгә бәйле хаталар. Республикадагы оешма-учреждениеләрнең исемнәрендәге хаталарны бу төркемгә кертергә була. Татар теле кагыйдәләре нормасыннан тайпылу мисаллары бу. Сүзләрне дөрес кулланмау, ягъни лексик хаталар да шушы төркемгә керә.

Хаталар юллап, җиңүче дип табылганнарны бүләкләү чарасы бу елның дүртенче кварталына билгеләнгән.

Штраф белән генә чикләнмиләр

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Шушы вакыт эчендә ЮХИДИ инспекторлары исерек килеш машина йөрткән 4 меңнән артык кешене тоткарлаган. Аларның 326сы исерек килеш икенче тапкыр рульгә утырган булган. «Юл фаҗигаләре саны кимесә дә, исерек йөртүчеләр мәсьәләсе элеккечә үк актуальлеген югалтмый. Бу проблеманы күзәтүче полиция хезмәткәрләре ярдәмендә генә хәл итеп булмас, ахрысы. Монда комплекслы эш алып барылырга тиеш», – ди Ленар Габдрахманов.

Бу урында Буа, Түбән Кама районнарын тәнкыйть сүзләре белән телгә алды ул. Полковник Габдрахманов фикеренчә, биредә алар гаебе белән килеп чыккан юл фаҗигаләре саны арткан, әмма җирле түрәләр куркыныч саннарны киметү өчен бернинди чара да күрмәгән.

Сүз уңаеннан, хәзер исерек килеш машина йөртүчеләр турында ЮХИДИ идарәсенең «Телеграм» каналына да хәбәр итәргә мөмкин. Алар республиканың һәр районында булдырылган. Ленар Габдрахманов фикеренчә, бу мәсьәләне хәл итүдә массакүләм мәгълүмат чараларының да өлеше зур. «Узган ел исерек хәлдә машина йөртүчеләрнең «хурлык тактасы»н булдырдык. Массакүләм мәгълүмат чарасында закон бозучы турында мәгълүмат белән беррәттән аның суд залындагы фотосы да басыла. Хурлыкка калу уңай нәтиҗә бирә – андыйлар гаебе белән килеп чыккан юл һәлакәтләре саны кими», – ди Ленар Габдрахманов.

Быел кагыйдә бозып каршы як юлга чыгучылар аркасында, 43 кешенең гомере өзелгән. Бу – кеше үлеменә китергән аварияләрнең 84,3 проценты дигән сүз. ЮХИДИ вәкилләре әлеге кагыйдә бозучыларга карата игътибарны арттыруларын әйтә. Быел 4 айда 5 мең машина йөртүчегә штраф салганнар. Шуларның 120се икенче тапкыр эләккән һәм машина йөртү таныклыгыннан колак каккан. «Икенче тапкыр эләккән һәм тизлекне кабат сәгатенә 60 чакрымнан арттырган өчен быелдан җинаять җаваплылыгы каралган», – дип искәртте Ленар Габдрахманов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БЕЗГӘ МОННАН НИ ЗЫЯН?

Белем сыйфаты

Татарстанның белем сыйфаты буенча илкүләм рейтингта күрсәткечләре белән мактана алмавы турында язып чыккан идек инде. Безнекеләр хәлләр алай ук начар түгел дисә дә, тәнкыйтьне бөтенләй үк танымый мөмкин түгел. Хаталарны ничек төзәтергә кирәклеген белем сыйфатын бәяләү буенча федераль институт директоры Сергей Станченко видеоэлемтә аша аңлатып күрсәтте. Әлеге рейтинг нәтиҗәләренең укучыларга, әти-әниләргә нинди йогынтысы бар соң?

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Нәтиҗәләргә үпкәләп яки гадел түгел дип карарга кирәкми, алга барырга этәргеч итеп карарга кирәк», – дип кисәтте Станченко.

Гаугалы исемлектә күпләрне республиканың компьютер куллану буенча нибары 44 нче урында булуы гаҗәпләндергән иде. Бездә техника ягыннан проблема юк. 2019 елда гына 7 нче урында торганбыз, нигә шундый бәя куйганнар?

– Күрсәткечләргә карасак, «Татарстанда компьютерлаштыруга игътибар кимегәнме әллә?» дигән сорау туар. Чынлыкта бернинди куркыныч әйбер дә юк, – дип тынычландырды Станченко.

Аның әйтүенчә, бары бәяләү алымнары үзгәргән. Әйтик, 2019 елда мәктәпләр өлешен информатикадан имтиханны – 9 нчы, ә узган ел 11 нче сыйныф укучыларының сайлавыннан чыгып билгеләгәннәр. Кыскасы, күбрәк бала сайлаган саен, исемлек башындарак буласың. Мәскәү чиновнигы моны профильле сыйныфларга да бәйләп аңлатырга тырышты. Янәсе, 10–11 нчедә IT профильле сыйныфларда укучылар компьютердан иркенләп файдаланса, башка балаларга информатика белән мавыгу мөмкинлеге җитеп бетми. Шартлар тудырылган җирдә укучылар информатиканы сайлый.

Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин бу уңайдан: «Рособрнадзорның бәяләү күрсәткечләре белән бәхәсләшергә дә була, – диде. – Монда шартлар тудыру турында әйтелде. Бездә барлык мәктәпләрдә компьютерлар җитә. Әмма бу барлык укытучылар да информатиканы сайларга тиеш дигән сүз түгел».

Соңгы елларда башлы балаларның илнең башка вузларына китүе еш телгә алына. Нигә читкә җибәрәбез, нигә үзебездә мөмкинлекләр тудырмыйбыз, дип борчылабыз. Исемлектә дә моңа игътибар иткәннәр. Абитуриентларның республика вузларын сайлавы буенча 2019 елда 14 нче урында торсак, узган ел, 69,9 балл җыеп, 22 нче урынга төшкәнбез. «Бездә күп яшьләр ил вузларына укырга керә, дип сокланып әйтерсез. Тик һәр төбәктә яхшы, дәрәҗәле вузлар булырга тиеш. Һичшиксез, алар Татарстанда бар. Әмма саннар әле тиешле дәрәҗәгә җитмәвен күрсәтә», – диде федераль белгеч.

Рейтинг 12 күрсәткеч буенча эшләнгән, шулай булгач, һәрберсе турында аерым сөйләргә була. «Мәгарифтә тигезлек» күрсәткече буенча республика 42дән 13 нче урынга сикергән. Тик Станченко монысында да әйтергә сүз тапты. Аныңча, олимпиада җиңүчеләренә генә өстенлек бирергә кирәкми. Татарстанның олимпиада җиңүчеләре саны буенча илдә тотрыклы рәвештә өченче урын тотуын беләбез. «Бөтен мәктәпләргә дә бертигез игътибар бирү яхшырак. Әгәр уку йортларына яхшы укытучыларны, укучыларны җәлеп итсәк, киресенчә, гомуми нәтиҗәләр начаррак булачак», – диде Станченко.

Имтиханнар, бөтенроссия тикшерү эшләре нәтиҗәләре буенча «икеле» алучыларның иң күбесе бездә булып чыкты. Бу уңайдан белгеч түбән күрсәткечле мәктәпләр белән эшләргә киңәш итте. Шул ук вакытта артта калучылардан бөтенләй котылып та булмаячагын искәртте. «Күрсәткечләрне яхшырту өчен, мәктәпләрдәге барлык укучыларның сәләтен барлау кирәк, кайчак күләгәдә калучылар да була. Монда һәр балага игътибар бирү турында сүз бара. Бу олимпиада җиңүчеләрен яки элита мәктәпләрен генә арттыру түгел!» – диде Сергей Станченко. Шулай ук белемне бәяләгәндә, имтихан тапшыручы 9 нчы сыйныф укучыларына ташлама ясамаска кушты. Сынау катгый булганда, тырышу теләге артачак, дип саный мәгариф түрәсе.

Рейтингтан нинди нәтиҗә ясарга? Акыллы башларны читкә җибәрмәскә, дәрәҗәле вузларны, информатика имтиханын сайлаучыларны арттырырга, олимпиада җиңүчеләрен өстен куймыйча, начар укыган балаларга игътибар бирергә… Килешергә һәм килешмәскә була. Тик чиновникның безнең бакчага таш атуында хаклык та бар. Иң яхшы мәктәпләргә иң яхшы укытучыларны билгеләү, заманча техника белән баету дигән нәрсә бар. Имтихан нәтиҗәләрен алсак та, ел саен иң көчле мәктәп, лицей укучылары югары баллар җыя. Көчсезрәкләрне тартырга вакыт. Минем балага нинди йогынтысы бар диючеләргә бары бер генә сүз: «Тырышып укырга!» Киләсе елда исемлектә нинди мөгез чыгарулары билгесез. Бу юлы компьютерларны санасалар, киләсе елга башкасын исәпләрләр. Хикмәт анда түгел, иң мөһиме – начар укучылар аз булсын, алган белемнең тормышта файдасы тисен.

Сәрия МИФТАХОВА

77

1941-1945

ҖИҢҮЧЕЛӘР

Онытмассыңмы?

Татарстанда узган сораштыруда яшьләрнең 70 проценты, «Россия белән ни өчен горурланасыз?» дигән сорауга җавап итеп, Бөек Ватан сугышында Җиңүне атаган. Бәйрәм алдыннан без дә яшьләрнең фикерен белештек.

Сәйдә МӨХӘММӘТҖАНОВА, җырчы:
– Минем өчен 9 Май ул – иң беренче чиратта, хәтер көне. Ел саен, бабамның фотосурәтен тотып, «Үлемсез полк»та катнашам. Без – яшьләрнең бу көнне, моннан 77 ел элек булган вакыйгаларны онытырга хакыбыз юк. Нинди батыр булган безнең бабаларыбыз! Безнең өчен, якты, тыныч киләчәк өчен күпме көч куйган, гомерләрен дә кызганмаган бит алар! Яшь буынны шушы тарихи хәтер, сугыш турындагы фильмнар, китаплар әхлакый яктан тәрбияли дип уйлыйм мин. Шуңа да бу турыда күбрәк сөйләнсен иде. Ләкин бүген, без хәтерлибез, без онытмадык, дип курыкмыйча әйтә алам.

Илмир ЯРУЛЛИН, укытучы:
– Җиңү көне кечкенәдән канга сеңгән, дияргә була. Ул чакта, бәлки, бөтен әһәмиятен аңлап бетермәгәнмендер дә мин. Тик ел саен бу көнне митингка бару, анда яңгырый торган җырлар, телевизор аша күрсәтелә торган фильмнар – барысы да хәтергә кереп, катлам-катлам җыелып барган. Инде хәзер гаиләм тарихы белән кызыксына башлагач, Җиңү көне бар кайгысы һәм шатлыгы белән аңлашыла. Әбиемнең әтисе сугышны узган, бабам ягыннан да катнашучылар, һәлак булучылар бар. Шунлыктан бу көн хәзер тарихи хәтерне яңарту көне буларак та кабул ителә. Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк. Бу сүзләр инде яхшырак аңлашыла. Миңа калса, Җиңү көне ул – үзеңне илең тарихына язып, илеңне аңларга этәргеч бирә торган бәйрәмдер. Үткәнебез белән тоташтыра торган күпер ул. Ләкин бүген халыкның карашы инде үзгә, чөнки буыннар алышына, һәр яңасы бу көннең әһәмиятен азрак аңлый сыман.

Алия ӘҺЛИУЛЛИНА, илкүләм «Ел студенты – 2021» бәйгесе җиңүчесе:
– Безнең гаилә өчен 9 Май – хәтер, кайгы һәм рәхмәт көне. Минем нәсел шәҗәрәмдә Бөек Ватан сугышында катнашкан өч бабам бар. Аларның икесе генә исән-имин килеш туган якларына әйләнеп кайткан. Бабамның әтисе сугышның бөтен ачысын, михнәтен, үз уйларын, хисләрен дәфтәргә язып барган, һәм ул кульязма бүгенгә кадәр сакланган. Мин ел саен шушы дәфтәрне кулыма алып, һәр юлын кат-кат укыйм, анда язылганнарны үзем аша кичерәм. Һәм, беләсезме, бабам тасвирлаган вакыйгалар бүгенге тормышны, тыныч һәм аяз күгебезне, җәмгыятебезне тиешенчә бәяләргә, кадерләргә өнди кебек. 9 Май – бөтен ил өчен әһәмиятле көн. Яшьләр исеменнән, без әби-бабаларыбыз күрсәткән батырлыкларны, илебезнең күпсанлы югалтуларын онытмадык һәм онытмаячакбыз, дип әйтә алам. Җиңү кыйммәте, тарихи хәтер югалмасын, безнең йөрәкләрдән җуелмасын өчен, аны киләчәк буынга тапшырып калу мөһим.

Рөстәм НАСЫЙБУЛЛИН, җырчы:
– Илебезнең иң зур бәйрәме инде ул – Җиңү көне. Бу көннең әһәмияте турында күпме генә сөйләсәң дә, аз тоела. Иҗат кешесе булгач, хисләремне җырга кушам. Минем репертуарда патриотик рухтагы җырлар аз түгел. Аларны башкарганда, икеләтә горурлык хисе кичерәм мин. Беренчедән, бабаларыбызның бәһасез батырлыгы өчен горурлансам, икенчедән, шушы җырларны сугышның шаһитлары – ветераннарыбыз алдында басып җырлый алуым белән бәхетле. Кызганыч, аларның сафы елдан-ел кими... Җыр – бик яхшы тәрбия чарасы да әле. Сугыш турындагы җырларның сүзләрен, бар мәгънәсен халыкка җиткерергә тырышам. Бигрәк тә бездән соң килүче буынга. Алар 9 Майның гади дата гына түгеллеген, илебезнең бүгенгесе өчен гаять зур әһәмияткә ия көн булуын аңларга тиеш.

Сезнең хакка, солдатлар!

Алар онытылырга тиеш түгел. Исеме, дәрәҗәсе булган сугыш геройлары гына түгел, җиңүгә бәһасез өлеш керткән гади сугышчылар да. 100 нче дистәсен ваклаучы Бөек Ватан сугышы ветераны, журналист, язучы Александр Малов яңа китабы аша укучыга әнә шул фикерне җиткерергә тели.

Александр Михайловичның «Слово пахарей войны» китабы «Җиңү волонтерлары» хәрәкәте активистлары ярдәме белән «Доброволец России» конкурсында откан грант акчасына дөнья күргән.

Татарстанның Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзасы Ольга Лукина Александр Малов белән 2018 елда ук танышуы һәм аның көчле рухына соклануы турында сөйләде. «Әлеге китапны чыгару теләге белән шул чактан бирле янып йөри иде ул. Һәм без, грант отып, Александр Михайловичка булышырга керештек. Бу эшкә битараф калмаганнарга зур рәхмәтемне белдерәм», – дип сөйләде Ольга.

Бөек Ватан сугышының бөтен ачысын, газап-михнәтен күргән Александр Михайлович үз чыгышын да хатирәләрен барлаудан башлады. «Сугыш башланганда без нинди илдә яши идек? 15 союздаш республика, 193 млн кеше. Шәһәрләрдә яшәүчеләр – якынча 25 процент, авылларда халыкның 75 проценты яшәде. Ә авыл кешесенә нәрсә? Кышын махорка белән җылына, җәен кайда су күрә, шуны эчеп сусавын баса. Чыдам, талымсыз халык. Сугышка да шулар китте. Шәһәр кешесенә бит заводында эшлисе бар», – дип сөйләде ул.

Китапның бурычы нидә соң? «Сигез дистә ел эчендә сугыш, батырлык, каһарманлык турында миллионлаган китап язылды. Бу өлкәгә мин дә кечкенә өлешемне кертә алдым. Беренче китабымда («Батырлар китабы». – **Ред.**) 25 герой турында сөйләп, аларның батырлыгын төрле яклап яктыртырга, ул геройларны киләчәк буын өчен маяк, үрнәк итеп күрсәтергә тырыштым. Ә бу китапның максаты бөтенләй башка. Монда – гади кешеләр, гади солдатлар. Алар күргән бар михнәт, кайгы һәм шатлык ничек бар, шулай, сугыш белән күзгә-күз очрашкан 17 яшьлек малай күзлегеннән язылган. Безгә чины, дәрәҗәсе булган геройлар, һичшиксез, бик кирәк. Ләкин аларның саны – 12 меңләп кеше. Һәм бу сан фронтта дүрт ел дәвамында көн саен һәлак булган солдатлар санына тигез. Сугыш нәтиҗәсен геройлар түгел, калган 34,5 млн солдат билгеләде. Бу китап алар турында», – дип аңлатты Александр Михайлович.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова, язучының киләчәккә дә ниятләре зурдан булуга киная ясап: «Александр Михайлович, Бөек Җиңүнең 80 еллык юбилеена кадәр яши алмам дип, бу китапны быел чыгарырга карар кылды. Шунда мин аңа: «Яшисез әле, сез яшәргә тиеш! Тагын берәр китап язарга кирәк сезгә», – дидем. Тагын язарга сүз бирде ул миңа», – диде.

Александр Михайлович, Җиңү, Хәтер көннәренең әһәмиятен, асылын җуябыз, ахры, дип тә борчыла. «Ялгышмасам, узган ел булды бу хәл. Сугыш башланган көн – бездә Хәтер көне бит инде. Шуны «бәйрәм итәргә» чакырдылар мине. Бераз утырганнан соң күңелле җырлар җырлана башлады. Моны карап утырырга сабырлыгым җитмәде – чыгып киттем. Җиңү көне дә кайберәүләр өчен шулай «бәйрәм итәр» өчен бер сәбәпкә әйләнеп бара. Хәер, сугышның нәрсә икәнен белмәүчеләр сугышта катнашканнар арасында да бар бит...» – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ИРЛЕ-ХАТЫНЛЫ ВЕТЕРАННАР:

«БЕЗ КҮРГӘННЕ СЕЗ КҮРМӘГЕЗ!»

Кукмара районының Өлге авылында ирле-хатынлы сугыш ветераннары Хәтирә апа белән Мөбарәкҗан абый Салиховлар яши. Шөкер, быелгы Җиңү бәйрәмен дә үз аякларында, шатланып каршы алалар.

Бергә гомер итүләренә дә 68 ел инде. Хәтирә апага бер айдан – 99, Мөбарәкҗан абыйга 96 яшь тула. Икесенең дә хәтерләре бик яхшы. Әле менә шушы көннәрдә генә район башлыгы килеп хәлләрен белгән, Җиңү көне белән котлаган. Май аенда алардан болай да кунак өзелми. Килгән кешене сөенеп каршылыйлар.

– Икебез дә шушы авылдан без. Күрше урамнарда гына яшәсәк тә, яшь вакытта бер-беребезгә игътибар ителмәгән. Насыйп ярлар булгач, соңлап кына гаилә кордык. Кияүгә чыкканда 30 яшемне тутырган идем инде, – ди Хәтирә апа. – Шөкер, Мөбарәкҗан абыең ипле кеше булды. Юкка-барга кәефемне кырмады. Бик аңлашып яшибез.

Алар бер-берләрен ярты сүздән генә дә түгел, күз карашыннан аңлый инде хәзер. Хәтирә апа әле дә картына үзе чәйләр әзерләп бирә, ашарга да пешерә икән. Тавыкларын да бетерми торалар. «Урамга чыккан саен, берәр йомырка алып керәм», – ди Хәтирә апа. Ә кызларының әти-әниләренә җылы ризыкны үзләре пешереп ашатасы килә. Күрше егетенә генә кияүгә чыккан Асияләре әнә шулай гомер буе әти-әнисен кадерләп яшәтә. Казанда яшәүче Әлфияләре дә һәр атна ял саен туган йортына кайтып йөри. Әле менә без шалтыратканда да Әлфияләре яннарында иде. Ул да әти-әнисенең әле һаман сугыш хәлләрен сөйләшүләрен әйтә.

Хәтирә апа искә ала:

– Авылдан дүрт кызны хәрби комиссариатка чакырттылар. Ул чакта миңа 19 яшь иде. Безне кем сугышка алсын соң, дип юл буе көлешеп бардык. Янәсе, буйларыбыз кечкенә. Тик соңыннан еларлык булды. Сәрбиҗамал белән мине сайлап алдылар. Буй кыскага карамадылар, иякне күтәреп, аяк очларына басып тордык. И еладык инде шул чакта. Сугыш күргән кешемени без? Әни ничек чыдар? Исән кайта алырбызмы? Елап ятып, берни эшләп булмасын аңладык. Башта Мәскәүгә җибәрделәр. Анда радистлыкка өйрәттеләр. Химки шәһәрендә разведчиклыкка укыттылар. Аннары ниндидер вагонга төялдек. Юл буе, әнием янына кайтарсыннар иде, дип теләдем. Тизрәк авылыма кайтасым килде. Тик булмады. Безне Ленинградка җибәргәннәр икән. Поезддан төшкәч, дошман күрмәсен дип, Ладога күлендәге боз өстеннән 70 километр шуышып бардык. Шулай итеп, Ленинград камалышына килеп кердек. Без күргәнне сез күрмәгез, кызым!

Хәтирә апа аэростатчылар частенда хезмәт итә. Киров исемендәге заводны аэростатчылар ярдәмендә немец самолетларыннан саклыйлар.

– Аэростат ул – эченә водород тутырылган, миналар беркетелгән трослар белән күк йөзен томалап, дошман самолетларына түбән биеклектән очарга комачаулаучы корал. Шарны җиргә төшереп, эчендәге водородны алыштыру безнең өстә иде. Кышкы суыкларда тимер тросларны ялан куллап тотып тартырга туры килә иде. Бияләйләребез ертылып бетәр иде, – дип сөйли Хәтирә апа. – Безгә тәүлегенә 125 грамм ипи, 75 грамм сохари бирерләр иде. Суыктан, ачлыктан, ял җитмәүдән шешенә идек. Аяк-кулларның көче калмады. Әмма без бирешмәдек. Дошманны җиңү теләге зур иде. Биредә без 24 татар кызы идек. Русча белмәгәч, безне «Не белмәс» отряды дип тә йөрттеләр. Ленинград камалышындагы 900 көннең яртысын мин дә күрдем.

Шунда күрсәткән батырлыклары өчен ул «Ленинградны саклаган өчен» медаленә лаек була. Хәтирә апага 1945 елның августында гына туган авылына кайту бәхете елмая. Алар Сәрбиҗамал белән икесе дә өр-яңа шинельләр киеп кайталар.

Мөбарәкҗан абый фронтка чакыру кәгазен 1943 елның ноябрендә ала.

– Безнең әти башта Суслонгерда була. Ул вакытларны бик искә аласы килми аның. Суслонгер сугыштан да начаррак иде, дигәне бар. Анда безнең авылдан да күп кеше була. Шактые үлә. Әти дә Суслонгерда чакта ук үлем белән күп тапкыр очраша. Бик каты җәберләүләргә түзәргә туры килә аңа. Ач килеш агач ташыйлар. Алар анда ачлыктан да тилмерә, – дип сөйли кызлары Әлфия. – Алты ай тулгач, әтине Калининград фронтына җибәрәләр. Әтине укчылар полкына пулеметчы итеп билгелиләр. Бервакыт ул аягы белән чокырга баса. Ә анда мина була. Аның ике аягы да яралана.

Мөбарәкҗан абыйга бик озак госпитальдә дәваланырга туры килә. Аяклары тиз генә төзәлми. Сугышка керәсе килсә дә, аны инде бүтән кертмиләр. 1944 елда авылына кайтарып җибәрәләр. Ул сугыштан «Германияне җиңгән өчен» медале белән кайта. Кайткач та, аякларындагы кыйпылчыкларны чүпләргә туры килә. Озак та үтми, сугыштан әтисенең үлгән хәбәре килә. Өй тулы кыз туганнары, әнисе бар. Мөбарәкҗан абый аяк авырта дип ятмый, колхозга каравылга эшкә чыга. Аннары инде әкренләп яралары төзәлгәч, тракторга утыра. Менә шул чакта Хәтирәгә күзе төшә. Кызны ошата ул. Тиз генә тәкъдим дә ясый. Тик Хәтирәсе бер генә әйтә: «Сабантуйда!» Мөбарәкҗан абый түземсезлек белән Сабантуйны көтә. Тик аңынчы кызны күзәтә. Егетләр белән шаярып сөйләшсә дә, янына якын китерми Хәтирәсе. Үз теләге белән килен булып төшмәсен аңлагач, Сабантуй кичендә Хәтирәне урлап алып кайта.

Олы кызлары Асия тугач, Донбасс якларына чыгып китә Салиховлар. Тик туган як үзенә тарта. Дүрт елдан Кукмарага кире кайталар. Матур яши алар. Ике кыз үстерәләр. Хәзер инде балаларының, оныкларының, оныкчыкларының игелеген күреп яшиләр. Әти-әниләре кызларына рәхмәт кенә укый.

– Аллаһы Тәгалә матур тормыш насыйп иткән безгә, – ди Мөбарәкҗан абый. – Кызлардан уңдык. Әлфия атна саен диярлек кайтып йөри. Асиябез гел яныбызда инде. Оныклар, оныкчыклар сөйдек. Шөкер итәрлек. Картайдык, диясе дә килми әле. Яшәү шундый рәхәт бит!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ОЗЫН ГОМЕРЛЕ БУЛАСЫГЫЗ КИЛСӘ...

Яшәү-көнкүрешеннән канәгать булмый аһ оручыларны Түбән Камада гомер кичерүче 92 яшьлек Гадилә әби белән таныштырыр идем. Тәвәккәллеге, үҗәтлеге, шул ук вакытта үтә дә сабырлыгы аңа күп кенә катлаулы хәлләрдән исән-имин чыгарга, гаиләсен сакларга, гомумән, яшәргә ярдәм иткән. Ә ул күргәннәрне яза башласаң...

Гадилә әби мине ишектән шикләнеп кенә кертте. Шулай булмый ни: мошенниклар котырып үрчи бит. Газета укырга яраткан әби, таныш исем ишеткәч, елмаеп куйды.

– Гафу ит, кызым, дерелдәвек пешерә идем. Балаларым бик ярата шуны. Ашасыннар, бик файдалы бит ул. Әле сезнең гәҗиттә дә витаминлы ризыклар ашарга кирәк дип язылган иде, – дип сөйләнә-сөйләнә, мине үз артыннан түр бүлмәгә әйдәкләде. – Башкортстан ягыннан мин, кызым. 1929 елда туганмын. Күзләреннән нур бөркеп торган, калын озын толымлы, йомры гәүдәле, уртача буйлы, кулларында ут уйната торган җор телле кыз диярләр иде минем хакта. Авылдагы чибәрләрнең берсе, кыскасы. Шуңа да минем арттан колхоз рәисе улы йөрде дә инде. Бик тә акыллы иде ул. Кавышу гына насыйп булмады...

Гадилә әби сугыш алды һәм сугыш елы истәлекләреннән берничә вакыйганы бәян итә.

Авыр хезмәттә

Егылып китәрлек фәкыйрь дә булмадык, авыз тутырып, икмәк тә ашый алмадык, шулай үтте яшьлегем. Гаиләдә өч кыз бала идек. 1935 елда әти алтын приискына эшкә ялланды. Юлда төпчегебез үлде. Начар яшәмәдек анда. Бер кат юдырылган комны апа белән әти тагын бер юдырта. Азмы-күпме алтын табыла. Аны махсус кибеткә тапшырабыз. Әни тагын бер кыз алып кайтты. Ләкин әти зәңгелә (цинга) чире белән авырый башлады. Аяклары шешенде. Аны хастаханәгә салдылар. Бер баруыбызда бездән: «Әтиегезнең киемен күрсәтегез», – диделәр. Күрсәттек. Күп тә үтмәде, әтине сак астында каядыр алып киттеләр. Тиз арада бер күнлек азык, кием-салым алып килергә куштылар. Илттек. Әти белән соңгы очрашуыбыз булды бу. Күп еллар узгач, оныгым аның 1940 елда үлгәнен ачыклады. Әтисез калгач, туган якка кайтырга булдык. Юлда әни әллә кайгыдан, әллә авыр хезмәттән авырый башлады. Аны да хастаханәгә салдылар. Ә безне балалар йортына урнаштырдылар. Апам Динә белән тимер мич тирәли елый-елый әйләнеп йөрүемне онытасым юк. Ашау такы-токы гына. Ялларда камыр ризыгы була. Аны бер яшьлек сеңлебезгә дип саклыйбыз. Кызганганнардыр инде, әни янына барырга рөхсәт итәләр. Бер уңайдан сеңлебез янына да керәбез. Аның бездән аерыласы килми, үкереп елый. Күчтәнәчебезне ашаганын карап торабыз. Икенче килүебездә тәрбияче аны безгә арты белән утыртты. «Ярсып елый сез киткәч. Исән икәнен күрдегез бит», – диде. Әни шактый вакыт дәваланды. Аягына баскач, юлыбызны дәвам иттердек. И, юлда кичергәннәрне сөйләп бетерерлек кенә түгел! Чит җирдә рус телен өйрәнүебез ерак сәяхәтебездә ярдәм итте. Берничә ай кайттык. Товар вагоны, баржа, йөк машинасы, җәяү... «Ярый әле авылыбызда йорт бар», – дип сөенде әни. Ишеккә, тәрәзәләргә аркылы кагылган такталарны каерып алдык та яңа тормыш башлап җибәрдек.

Әни эшкә урнашты. Безгә каралты-курадагы хезмәт йөкләнде. Әмма сугыш башланды. Миңа 12 яшь тулып килә. Шул ук елны колхоз эшенә чыкты авыл яшүсмерләре. Ярый әле сыерыбыз бар. Бәрәңге алтынга тиң хәзинә булды. Үлән, урман сые алып калды безне ул елларда. Ә күпме бала ачлыктан шешенеп үлде. Кияргә кием дә юк бит. Без ул яктан бераз хәлле идек, әни алтын приискында эшләгәндә кием-салым алгалады. Чабатадан йөрдек. Ул бик тиз туза иде.

14 яшемдә мине һәм авылдан берничә яшүсмерне урман кисәргә алып киттеләр. Урыс авылы. 4 кыз, ике малайны бер йортның мунчасына керттеләр. Фатир хуҗасы бик кызганды безне. Диләнкегә урман эченнән шактый озак керергә кирәк. Юан агачларны кисәргә кушалар. Төбе җирдән биек булмаска тиеш. Аны аударгач, ботакларыннан арындырырга, аларны тәртип белән өяргә кирәк. Аннан агачны берничә урыннан кисеп, урманнан чыгарабыз. Кыз балалар түгел, ир-атлар өчен дә авыр хезмәт бит бу. Ә план зур: кеше башына 38 кубометр. Шуны үтәмәсәң, паек бирелми. Кая инде ул план үтәү! Бервакыт ашарга бетте.

Автор фотосы

Фатир хуҗасы безгә качарга кушты. Ике юл бар икән: берсе – урман эченнән 30 километр, икенчесе тау аша. Юлда чабата тәмам таушалды. Ул елларда бүреләр күп иде. Өйгә кайтасы килү теләге шулкадәр көчле, туктамыйча алга атлыйбыз. Красный Ключ дигән авылга килеп җиттек. Мин урысча белгәч, тәрәзәсендә ут шәүләсе күренгән йортның ишеген шакыдым. И, бар да инде дөньяда мәрхәмәтле кешеләр! Керттеләр. Хуҗа әйтә: «Бездән ерак түгел чүплек бар. Анда мукшы чабатасы булмый калмас. Бәлки кием-салымга да юлыгырсыз, барып кайтыгыз әле». Безнең чабата-киемнәрне мич янына куйды, ашарга бәрәңге бирде. Чыннан да, кияргә яраклы чабата да, кием дә таптык. Сөенә-сөенә тагын юлга кузгалдык. Машина юлына чыктык. Бер йөк машинасы туктады да, шофер кайдан килүебез, кая баруыбызны сораштыра башлады. Безне эзләячәкләрен беләбез бит. «Абый, утырт, зинһар. Менә шушында тотып атсалар да, бүтән урман кисәргә барачагым юк!» – дидем. «Юлда милиция туктатса, малайлар йөк төяүче дияр, сезне юлда очраттым, диярмен», – ди бу. Күпмедер баргач, милиция туктатты бит. «Капчыгыгызда нәрсә?» – дип сорый берсе. Баксаң, Красный Ключ авылындагы кием складын басканнар икән, бурларны эзләве боларның. Җиңел котылдык. Авылга кайтып җитеп, өйгә аяк басуга, идарәгә чакыртып алдылар. Безнең качу турында хәбәр үзебездән алда килеп җиткән иде.

«Синең өчен планны кем үтәр?» – ди колхоз рәисе. «Ярар, барам. Ләкин сез минем авыру әнине карагыз, сеңлемне укытыгыз, сыерга азык хәстәрләгез, дәүләткә ит, сөт, йомырка тапшырыгыз», – дидем. Калдырдылар. Ә дустым китте һәм бүтән әйләнеп кайтмады.

Тыныч тормышта

Сугыш беткәч, Динә апасы Казахстанга чыгып китә. Аннан туганнарын да чакырта. Гадилә, чын мәгънәсендә, авылдан кача. Апасы гаиләсенә барып сыена. Анда булачак ире Миңнегарифны очрата. Ул иренең туганнары турында шуның кадәр җылы хисләр белән искә ала, әйтерсең сүз үз әнисе, апалары, балалары хакында бара.

Иренең бертуган Ибраһим абыйсы Түбән Камага кайтып төпләнә дә башкаларны да үз янына тарта. Шулай итеп, 1969 елдан алар Түбән Камада гомер кичерә. Гадилә әби, лаеклы ялга чыкканчы, массакүләм шиннар заводында хезмәт куя.

Матур яши алар. Миңнегариф абый гына бакыйлыкка иртәрәк күчә. Гадилә әби кызын һәм улын да җир куенына сала. Фаҗигале рәвештә вафат булган кызының мәктәп яшендәге ике баласын үз канаты астына ала, аларга югары белем бирә. Бүген Рамиле белән Гөлнарасы, оныкчыклары өчен иң кадерле нәнәй булып яши.

– Аллаһым яшьлегемдә биргән сынаулары өчен картлыгымны бәхетле иткәндер, дип сөенәм. Бүген бар теләгем – сугыш булмасын. Япь-яшь балаларның каны коелуын ишетеп, йөрәгем әрни. Югыйсә тыныч тормышта яшибез бит. Чит-ятларга акыл сата алмыйм, әмма шуны әйтәм: минем кебек озын гомерле булырга теләсәгез, аек акыл белән эш итегез, тыйнак яшәгез, бер-берегезне хөрмәт итегез, кешенең яман сүзенә ышанмагыз, сабыр булыгыз! Бу теләгем сиңа да, кызым, – дип, аркамнан сөеп озатып калды Гадилә әби.

Бишенче каттан төшеп-менеп йөрү җиңел түгелдер, шулай да ул подъезд төбендәге утыргычта утырырга, күршеләре белән аралашырга ярата. Йөзеннән нур балкып торган, кесәсендә һәрвакыт «куян күчтәнәче» булган Гадилә әбине йортта яшәүче балалар да таный, елмаеп сәламли.

Нурисә ГАБДУЛЛИНА

ҖИҢҮЧЕЛӘР

Гаҗилә әби шигырь яза

Автор фотосы

Һәр мәҗлеснең үзенә бер бизәге, үзенчәлеге була. 95 яшьлек Гаҗилә әби Атакаева бүген юбилеена килгән кунакларны үзе язган шигырьләрен укып таң калдырды.

Гаҗилә апа әле дә матур-матур шигырьләр яза икән. «Егылсам да, үзем торып киттем…» – ди ул бер шигырендә, көчле рухлы булуын раслап.

Яшь чагында Иркутск якларында бетон да салган, көчле агымлы Ангара суында кер чайкаган. Озак еллар Казахстанда яшәп тә ныгыган якташыбыз. Шәл бәйләгән, юрган тышлары да теккән. Әле дә тегү машинасын еш «кабыза». Аны, өч көн чиратта торып, 1950 елда Иркутскида алган булган.

– 13 яшемдә атка сука тагып, җир сөрдем, – ди бүген Чирмешән районындагы Югары Кәминкә авылының иң өлкән кешесе. – Иртәнге сәгать өчтә эшкә керештек. Ашыйсы килә башлый. Сәгать 10да гына нәрсәдер алып киләләр иде.

– Без Казахстанда яшәгәндә өч сыер, җиде ат, кырык-иллешәр баш сарык һәм кәҗә асрадык, – ди юбилярның Кара Чишмәдә яшәүче кызы Гөлнур Шәкүрова. – Әти дә, әни дә уңган булдылар, безне эшкә өйрәтеп үстерделәр. Мин өченче сыйныфта укыганда ук сыер сава башладым. Хәтерлим әле: әни Татарстандагы туганнарга кәҗә мамыгы җибәрә, ә безгә посылка белән бал килә иде.

Искитәрлек: 95 яшьлек әби быелтыр да бәрәңге бакчасында чүп утап, балаларына булышкан. Әле бит аның бер аягы юк. Җирдә шуышып, инде 18 еллап шулай эшләгән. Хәзер коляскада гына хәрәкәтләнсә дә, тик торырга чит енсенә, тегү эшеннән тәм табып яши икән.

Атакаевлар Югары Кәминкәгә 25 ел элек кайтып төпләнгәннәр. Тумышы белән Чуаштан кешесе Минаҗетдин абзый 2007 елда вафат булып, монда җирләнгән. Хәзер карчыгы Гаҗилә әби күбрәк янәшәсендәге улы Минсәгыйть, килене Лидия тәрбиясендә.

– Без аларга, аеруча җиңгәбез Лидиягә бик рәхмәтле, әнине карау мәшәкатьләре иң элек аларга төшә, – ди әнисенең юбилеена Кара Чишмәдән килгән Мөзәянә Минапова. – Биш туганым булуга да сөенәм.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: Лидия Атакаева – немец милләтеннән.

– Югары Кәминкә халкы мине яхшы кабул итте, – ди ул. – Еш кына мәҗлесләргә чакыралар, аларга барам, дисбе тартам, намаз да укыйм. Бераз кыенрак булса да, татарча аралашам.

Сәгыйть һәм Лидия җиде бала үстергәннәр, алтысы, шөкер, исән-саулар.

Гаҗилә Атакаевага район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илгиз Шәмсетдинов Россия Президенты һәм район башлыгы исеменнән котлаулар ирештерде, бүләкләр тапшырды. Социаль яклау бүлеге начальнигы Рушания Әхмәдуллина, Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Мингали Минһаҗев та матур теләкләрен юлладылар. Сыйлы, күркәм табын янында башкалар да сүз алды.

– Без Гаҗилә апа шигырьләреннән альбом да ясадык, – дип мактанды мәдәният йорты хезмәткәре Рабига Фатыйхова.

– Сезгә дә минем кебек картаерга язсын, – ди юбиляр. Шуңа исем китә: бу кадәрле кунак безне ничек табып килгән дип гаҗәпләнгән булды.

Беләләр, беләләр, табалар сезнең кебекләрне, Гаҗилә апа!

Кадыйр ГОМӘРОВ.
Чирмешән районы
Югары Кәминкә авылы

Тигезлектә картаю – бәхет ул

Чистай районының Кызыл Ялан авылында 61 ел бергә гомер итүче Вәзилә апа белән Әкрәм абый Мусиннар гаилә учагын бүген дә сүндермичә, бер-берсенә терәк, кирәк булып, матур гомер итәләр. Аларның балачагы бик күпләрнеке кебек уза: ашарга такы-токы, кияргә кием юк. Сугыштан соңгы авыр еллар була шул.

Әтисе фронтка киткәндә, Әкрәм абый биш яшендә генә була. Аны нишләптер озатырга уятмыйлар, уянгач, елый-елый, кыр капкасына хәтле чаба, ләкин әтиләре киткән була инде. Гаилә берничә хат ала, шуннан соң «хәбәрсез югалды» дигән язу гына килә. 1947 елның җәендә әнисенең аягы сына. Ул эшли алмагач, малайга ике ат белән пар җирен себерергә кушалар, аңа бу вакытта нибары 11–12 яшь була. Талкыш мәктәбенә йөреп укып, 7 нче сыйныфны тәмамлый. Зурлар белән беррәттән авыр эшләрдә эшли. Әтисезлек нык сиздерә. Әтиле малайларга кызыгып үтте инде яшь чаклар, ди ул. Чабаталы балачагы, кычыткан, алабутадан пешергән ашның, черек бәрәңгедән пешерелгән кәлҗемәнең тәме, елга ярлары буенда сары балчыктан «күмәчләр» ясап ашауларын моңаеп искә ала.

Балтыйк җирләрендә армия хезмәтен үтеп кайта. Аннан Чистай МТСында тракторчылар әзерләү курсларында укый, шуннан тимер атны җигә. Яшьләр күрше авылга аулак өйләргә, кичке уеннарга да баралар. Бер баруында Уракчы авылы кызы Вәзиләгә күзе төшә. Кыз – Нәҗметдин бабай белән Зәйтүнә әби гаиләсендә өченче, төпчек бала. Башлангыч белемне туган авылында ала, 7 сыйныфны күрше Талкыш авылына йөреп укый. «Ашарга, кияргә юк, чабата киеп, бозлы суларны ерып, кар-буран, яңгыр дими, укырга йөрдек», – дип искә ала ул. Алар гаиләләре белән Чулман болыннарына көтү көтәргә китәләр. Яшьли кул арасына кереп, бөтен эшне өйрәнеп, белеп үсә. «Чалгысын да, балта-чүкечен дә, пычкысын да тоттык, белмим дип тормадык», – ди ул.

Ике яшь йөрәк бергә кушылгач, тормышны бергәләп, төпкә җигелеп тарта башлыйлар. Әкрәм абый – тракторда, Вәзилә апа төрле эшләрдә эшли. Бербер артлы мәхәббәт җимешләре – Гөлсинә, Әлмирә, Рәйсә, Әдһәм дөньяга килә. Балалар үстергәндә каенанасы бик ярдәм итә. Вәзилә апа үзе дә бар яктан да килгән: тегү, чигү, бәйләү дисеңме, җырларга-биергә дә бик оста, кирәк чакта гармун алып сыздырып та җибәрә. Нинди эшкә алынса да, җиренә җиткереп башкара. Комплекс төзелеше вакытында пешекче була, аннан шунда ук терлекчелектә эшли. Мәктәптә идән юучы да, кочегар да, пешекче дә була. Әкрәм абый, пенсиягә чыккач, авыл имамы вазыйфасын башкара.

Әкрәм абый белән Вәзилә апа бер дә сынатмыйлар. Йорт та өлгертәләр. Балаларның укып, һөнәр алып, туып-үскән, әти-әниләре гомер иткән җирдә төпләнеп калулары да ата-ананың дөрес тәрбия бирүеннәндер, минемчә. Бала югалту хәсрәтен кичерү генә бик авыр булгандыр. Кырык сигез яшендә вафат булган уллары турында һәр көн диярлек моңаеп искә алалар. Хәзер инде берләнбер улларының тол хатыны Гөлназ белән тату гомер итәләр. Киленнәре бик ачык, сабыр, ярдәмчел һәм уңган.

Бүген Мусиннарның 9 оныклары, 11 оныкчыклары бар. Яшь буын өчен үрнәк булырлык гомер кичерә алар. Бер-берсен күз карашыннан, ярты сүздән аңлыйлар. Икесе дә – биш вакыт намазияләре, ураза тотып, ел саен Аллаһ ризалыгы өчен корбан чалалар. Ачык йөзле, киң күңелле, ярдәмчел булганнары өчен аларны туганнары да, күршеләре дә, авылдашлары да хөрмәт итә. «Тигезлектә картаю һәркемгә дә насыйп булмый. Без бүген әнә шунысы белән дә бик бәхетле», – диләр.

Резидә ВӘЛИЕВА.
Чистай районы Кызыл Ялан авылы

Автор фотосы

Йолдызлы капкалар

Авыл капкаларына кадакланган кызыл йолдызларны күргәнегез бармы сезнең? Ә аларның сөйләшкәннәрен? Минем бар. «Кешеләрнең капкаларына күктән йолдызлар төшеп кунган, ә безнең матур капкабызга юк», – дигән балачак уйлары ераклашып, үсә төшкәч, дөньяның асылына төшенә башлагач. Ил чигеннән күзгә күренмәс ераклыкта урнашкан туган төбәген саклар өчен хәләл каннарын агызган авылдашларымның батырлыгын, фидакарьлеген, исән-сау әйләнеп кайтканнарының тыйнаклыгын икенче яссылыкка салгач. Йолдызлы капкалар яныннан үткәндә, күңелегез пәрдәләрен ачарга онытмагыз, ишетми калмассыз…

***

– Исәнме, күрше!

– Шөкер! Олыгаям, ә син һаман да япь-яшь, тик…

– Кыенсынма, хакыйкатьтән кыенсынырга ярамый: әйе, мин әле дә егерме биштә, бары исән генә түгелмен.

– Эх, бу каһәр суккан сугыш!

– Яши-яши, бер бездән генә тормаган әйберләрнең да булганына инангансыңдыр.

– Алтмышны уздым бит, әзме-күпме дөньяның серләренә төшендем кебек. Йөрәк әрнүен генә туктатып булмый, сугыш ярасы гомерлеккә салына икән.

– Яра дигәннән, искә төшерүем өчен гафу ит, баш өянәкләрең еш кабатланамы?

– Ай саен, күрше. Арада бик көчлеләре дә булып китә. Дәвахәнәдән соң бераз җиңеләйгән кебек тә, барыбер кире әйләнеп кайта.

– Зөләйхага да җиңел түгелдер. И-и, мин әйтәм, бик чая иде ул синең…

– Чая гына түгел, түзем дә булып чыкты Зөләйхам. Ничә еллар буе инвалид ир көен көйләп яшәве җиңел түгел икәнлеген чамалыйсыңдыр…

– Зөләйхаларыбыз булганга, җиңү яулангандыр да.

– Син хаклы, күрше! Синең Зөләйхаңның да минекеннән калышкан җире юк иде бит. Үзе чибәр, үзе уңган, сабырлыгы гына ни тора! Гомере буе исемеңә тап төшермәде, синнән башка берәүдән дә наз-иркә күрмәде. Сугышка кадәр туган ике улың, бер кызың ятимлекне татымасын өчен бөтен көчен салды.

– Сезгә рәхмәтләрем чиксез, күрше генә булсагыз да, тугандай якын итеп, ярдәмегездән ташламадыгыз. Йортыбыз янгач, әллә күпме вакыт үзегезгә сыендырып торганыгызны, Зөләйхаң калага барса, балаларыбызга пардан кием-салымын алып кайтканын, киез итекләреңне аягыңнан салып, безнекеләргә бирүләреңне, тагын-тагын әллә күпме яхшылыкларыгызны онытырга мөмкинме соң?! Аларның хәлен җиңеләйтер өчен, җир астын тишеп чыгардай була идем!

– Бергә үскән, бергә ярлар сөйгән, бер җырларны көйләп йөргән егетләр ич без, үзең миннән дә уздырып та җибәрер идең!

Күз яшьләренә буылып, капка төбеннән кузгалып китмәкче идем, илаһи моң тавышы мине яңадан урыныма утыртты.

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә.
Айга менеп, түбән карап,
Сине күрәсем килә…

Бөек Ватан сугышында Җиңү юбилее алдыннан капкаларга кадакланып киткән ике йолдызның күңеленнән агылган моңын мин генә түгел, бөтен галәм тын калып тыңлады. «Зөләйха» җырын сөйгәннәре шул исемне йөрткәннәр генә, бәлки, шулай йөрәккә җиткереп көйли торгандыр? Әллә аңа иртән кызарып чыккан таңның, кичен кызарып сүнгән шәфәкънең сихри матурлыгы, һәр мизгеленең мәгънәсе, юанычы, зәвыгы, бер генә була торган яшьлек язы авазлары салынганмы? Бәлки, бу илаһи җыр бирелгән гомерне сугыш-михнәтләрсез, югалтуларсыз, шатлык-сөенечләрдә, тиң ярың белән гаиләдә балалар тәрбияләп, тыныч ил-җирләрне гизеп, яраткан һөнәреңә ия булып яшәү ноталарыннан торадыр? Җавап табуы кыен. Тик шулай да бер әйбер аермачык булып ярылып ята: ул да булса – сөю, мәхәббәт, ярату. Шушы мөкатдәс хисләр кешеләргә канатлар тагып, күкләргә күтәрә, күңелдә җыр-моң яралта, амбразураларга ташландыра, бозлы котыпларны эретә. Шушы мөкатдәс хисләр хыянәттән саклый, үлемне җиңә, хәтта җанны фида кылдыра.

Ике йолдызның берчә моңланып, берчә гәпләшеп алуларына башка йолдызлар да кушылды. Киләчәк буынга әйтер сүзләре дә бар иде аларның.

Зур корбаннар һәм чиксез газаплар бәрабәренә яуланган Җиңү байрагына тап төшермәгез! Тыныч тормышның, гаиләгезнең, якыннарыгызның кадерен белегез, гомерләрегезне заяга үткәрмәгез! Яшәүне әзер бүләк дип кабул итсәк тә, адәмчә яшәр өчен, бик күп хезмәт салырга кирәк. Һәр көн тырышлык сораганын белеп яшәгез. Бөтен акыл ияләренең сүзләрен укып та, ятлап та бетереп булмый. Ләкин яхшыны яманнан аера бел, вөҗданыңа хыянәт итмә, Туган илеңне сөюдән беркайчан да туктама, шул вакытта ул да сине сөяр!

Люция ӘБЛИЕВА

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

КҮҢЕЛ ҺАМАН КИТЕК

«Сугыш чоры ятимнәре турында язучылар, зарланучылар шактый, ләкин колак салучылар гына юк. Хөкүмәт җитәкчеләре безнең гозерне искә алмый. Бәлки аларның әтиләре сугыш кырында башларын салмагандыр яки, сугышта булып та, исән-сау әйләнеп кайткандыр, әтиләр канаты астында рәхәттә яшәгәннәрдер. Син авыл ветераннары рәисе буларак, шул турыда яза алмассыңмы дип килдем», – дип сөйләнә-сөйләнә килеп керде Гомер абый.

– Әтием Миңнегалиев Махубрахман Миңнегәрәй улы 1909 елда Кормаш авылында туган. 1941 елның июнендә ике баланы һәм әнине калдырып, фронтка киткән. Сеңлемә – яшь ярым, ә миңа алты яшь иде. Ул көнне мин яхшы хәтерлим. Урамда шаулашкан тавышлар ишетелде, йөгереп чыктык. Капкаларга нindидер кәгазьләр ябыштыралар, Герман сугыш башлаган икән, дип елашалар.

Әтигә сугышка китәргә дигән хәбәр килде. Көн матур иде. Әнигә ияреп, әтине озатырга Теләнче Тамакка бардым, елап калдык. Киткәннән соң ике генә хаты килде, шуннан соң хәбәр алмадык. Сеңлем декабрь аенда вафат булды. Авыргач, аны больницага җибәрмәделәр, чөнки әни бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләде дә эшләде. Әни мескен, колхозда «таяк»ка эшләп, түзә алмаслык авыр шартларда, ачлы-туклы, өшеп-туңып, мине тәрбияләде. Фронт өчен дип төрле заемнар җыя башладылар. Әни өйгә кайткач, күз яшьләре түгеп, ул акчаны каян, ничек итеп табып түләргә икән дип аптырый иде. Һәр көнне кәнсәләргә чакырып интектерәләр, эштән арып кайтып, ял итәргә дә вакытлары калмый иде. Ул елларда күргән газапларны искә төшерсәм, әле дә тетрәнеп куям. Ничек кенә исән калганбыз икән?

Салам түбәле, ярым җимерек өйләрдә кышкы зәмһәрир салкыннарда салам ягып (анысы да юк бит әле аның, фермадан маллар астына җәйгән саламнарны алып), ачлы-туклы яшәп, интегеп, бер телем ипигә зар булып яшәвемне һич тә оныта алмыйм.

Сугыш елларында безне табигать кенә коткарып калды, туендырды. Болыннан кузгалак, песи борчагы, кукы, кычыткан, балтырган, яз көне черегән бәрәңгедән кәлҗемә ашап тукландык. Әрәмәдән шомырт җыйдык. Язны, җәйне түземсезлек белән көтеп ала идем.

Әти сугышка кадәр ат караучы булып эшләде. Мин дә аның янына барып, колыннарга, атларга карап сокланa идем. Әти сугышка киткәч, әнигә дә карарга насыйп булды. Кышын коедан чиләк белән су алып, атларны эчертәләр, җәй буе көтү көтәләр иде. Ул вакытларда мин дә атка атланып, әзрәк әнигә ат куышырга ярдәм итә идем.

1945 елда сугыш беткәч, солдатлар кайта башладылар. Мин дә урамга йөгереп чыга идем дә әтине каршылармын дип өметләнә идем. Гомерем буе әтине көтеп яшәдем. Һавадан самолет очкан чакта, әти кайтмый микән дип, артыннан чаба идем. Мин генә түгел, авылыбызда әтисез калган балалар барыбыз да яу кырыннан кайтмаган әтиләрне көтеп яшәдек. Аларның кабере дә юк бит. Кайда, кайчан, ничек үлгәннәре турында да белмибез.

Әтисез үсү үзен һәрчак сиздерде. Мәктәптә яхшы укысам да, әнине ташламадым, белем алуны дәвам итә алмадым. Әнигә кирәк булыйм, дидем, алар бернинди ярдәм күрмичә үлеп киттеләр бит. Урыннары оҗмахта булсын.

1947 елның июль башында безнең өйгә колхоз кәнсәсен күчерделәр. Шул елдан башлап, мин ныклап эшкә керештем дә инде. Эшләргә бик яраттым, үҗәт, тәвәккәл булып үстем. Әти урынына калган малай буларак, төрле һөнәрләргә өйрәндем, дөресрәге, тормыш мине үзе өйрәтте, 60 елдан артык хезмәт куйдым. Өйләнеп, өч малай, ике кыз тәрбияләп үстердек. Өч улым да армия хезмәтендә булдылар. Кече улым Раиф Әфган сугышында катнашты. Ул вакытта тынычлап йоклау да эләкмәде.

Сугышта һәлак булганнарның акча кенәгәләренә балалары дәгъва итә ала дип әйтелгәч, мин дә көттем, ләкин нәтиҗәсе генә булмады. Әтиләре сугыштан кайтып, әтиле булып яшәгәннәргә фатирлар, машиналар, югары пенсияләр бар. Тол хатыннар, төрле хәйләләр корып, ялган белешмәләр юллап, һаман да фатир алалар. Ләкин бу фатирлар балаларына калгач, туган белән туганнар ызгышып-талашып беттеләр, хәзер бер-берсе белән аралашмыйча, дошманлашып яшиләр. Бәлки, алар үлгәч, фатирларын кире кайтарырга кирәк булгандыр? Ел саен Җиңү бәйрәмендә күпме ярдәм оештырыла. Бәлки без– ятимнәргә дә өлеш чыкса, начар булмас иде. Безнең ни гаебебез бар соң? Әтиләребез шушы якты, матур, мул тормыш өчен көрәшеп һәлак булдылар бит. Ул басуларда, окопларда, сазлыкларда, елгаларда үлеп калган солдатларны кемнәр генә барлап бетерсен инде? Кайберләренең каберләре дә билгесез бит. Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый, дисәләр дә, хәбәрсез югалганнарны нигә онытабыз соң?

Сугыштан соң авылларны, шәһәрләрне аякка бастырган буын түгелме соң без? Әйе, без сугыш яраларын дәваладык, әмма «җәннәт» бакчасында уйнап үсмәдек. Өлкәннәр белән бергә сугыш камытын бик иртә кидек, ач-ялангач килеш колхоз кырларында, терлекчелек фермаларында эшләдек, урман кистек, торф чыгардык, көнне төнгә ялгап эшләдек. Әмма бу чор балаларына чират һаман җитми, дәүләт аларны күрмәмешкә салыша. Әтиләре кайтмаган ятим балалар, дәүләт тарафыннан бәяләнә алмаганга, бик рәнҗи. Хәзер өлкән яшьтә булсак та, күңелләр һаман китек. Инде без дә 90га җитеп киләбез. Сугыш ятимнәре бармак белән генә санарлык калды. Мәсәлән, Кормашта – берәү, Шәрләрәмәдә – дүртәү. Сугыш чоры балалары барлыгы кырыклап булса да (бу өч авылга – Шәрләрәмә, Сөлек, Кормаш), ятимнәре 7–8 генә калды. Тыл ветераннары да елдан-ел сирәгәя. Аларның да саны 16 гына.

Хәзерге вакытта, Аллаһка шөкер, ачлыкта да яшәмибез анысы, әмма барыбер хәтер кала. Без – сугыш чоры балалары әтиләребез өчен ярдәм көтеп калабыз. Бу сүзләремне 1933 елдан башлап туган балалар исеменнән әйтәм…

Гомер абый бу язманы газетага җибәрүемне үтенде. Сөйләгәндә күзләреннән аккан яшьләрен тыныч кына кабул итә алмадым, ризалаштым. Башыннан үткән кешегә Алла ярдәм бирсен, яңадан сугышлар күрергә язмасын дигән теләктә калам.

Роза ШӘЙГАРДАНОВА.
Сарман районы

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

НӘСЕЛДӘН КИЛГӘН ИМАН

Шәле авылы – Татарстанда иң зур татар авылларының берсе. Гомер-гомергә дини авыллардан санала, өч мәчете, мәдрәсә бар. Иске мәчетнең 140 елга якын тарихы барлыгы билгеле. Ике мәхәллә мәчетенә хәзерге көндә 150 кеше йөри. Мәдрәсәдә 20 хатын-кыз, 23 ир-егет, 37 бала белем ала.

Кеше үз язмышын дин белән бәйләсә, ул, мин дөрес юлдамын, дип бәяли. Шулай булгач, бабайларыбызның кыйбласы дөрес. Менә дөрес юлдан киткән, кыйбласы туры булган авыл имамы Хәмзин Мансур Хөсәен улы турында сезгә дә белдерәсем килә. Бу кешегә авылда барысы да хөрмәт белән карый. Авылда Мансур абый игелек кылмаган бер генә кеше дә юктыр. Ул игелекне кеше күрсен, сөйләсенгә эшләми, ә йөрәге шундый аның. Бу сабыр холыклы, тыйнак, акыллы кешенең елмаюы шунда ук сине әсир итә. Мансур абый – бишенче буын имам. Атасының әтисе Мөхәммәтхәсән 30 елдан артык авылыбызның беренче мәхәллә имамы, ә бертуган энесе Мөхәммәтгали икенче мәхәлләнеке иде. Мөхәммәтхәсән белән Мөхәммәтгалиләрнең әтиләре Хәмзә бабай да, аның атасы Зәгъфәр бабай да, аның атасы Мәхмүт бабай да имамнар булганнар.

Мансур абый җиде буын бабасын белә. Аларның нилар белән шөгыльләнгәннәрен дә өйрәнгән. Хәзерге вакытта аның бабалары исеме белән бәйләнгән чишмәләр, басу исемнәре, сулыклар бар. Мансур абый аларны бик кадерләп искә ала һәм саклый.

Мәктәптә укыганда ул аеруча география, тарих фәннәрен бик яраткан. Хәзер дә кайсы илнең кайда урнашканын, нинди баш шәһәрләре, кайда нинди казылма байлыклары барлыгын бик тиз, төгәл әйтеп бирә. Әдәби китаплар да бик күп укый. Мансур абый – һәрьяктан белемле, күркәм кеше. Аның белән сөйләшеп утыру – үзе бер гомер. Ул дин тарихын бик яхшы белә. Үзенең калган гомерен дин юлында үткәреп, аны авылдашларына тарата.

Алдагы гомер бит рәхәт кенә узмаган. Мансур абыйга – 4, энесенә 2 яшь булганда, әтиләре ташлап китә. Сугыштан соңгы еллар. Сугыш яралары да төзәлеп җитмәгән, ә алар әтисез. Әниләре эштә. Мансур ике яшьлек энесе Мәхмүтне җитәкләп, тавык фермасына эшкә бара. Шунда аларга ындыр табагында эшләп йөрүче әтиләре очрый. «Әти, әти», – дип талпына алар. Әти кеше сүрән генә эндәшеп китеп бара. «Ул сезне күреп бетермәгәндер, башка вакытта янына барып, кычкырып эндәшегез», – дип, балаларын юата Мәсрүрә апа. Бу хәл күп тапкыр кабатлана. Ана балалар күңеленә үчлек оеткысы салмый. «Ул – сезнең әтиегез, сезне ярата», – дип инандыра. Әтиләре гомер буе үзе генә яши, ләкин Мансур абыйлар аны ташламыйлар, соңгы юлга да үзләре озаттылар. Аннан аталарының әтисен, 96 яшендәге бабайларын да Мансур абый карап җирләде. Ә бабай өендә үги әби белән инвалид абыйсы калды. Безнең имам аларны үз йортына алып менеп тәрбия кылды, бакыйлыкка да үз нигезеннән озатып җибәрде.

Имам Мансур абый язмышыннан беркайчан да зарланмый. Ул – түземле, бик мәрхәмәтле кеше. Аның өчен туганнарыннан да, авылдашларыннан да якынрак кешеләр юк. Имамыбызның

бар кешегә дә карашы бертөрле. Ул һәр кешене хөрмәт итә, игътибар белән тыңлый, гозерләрен үтәргә тырыша, һәрвакыт ярдәм кулы суза.

Аның һәр адымы туры, сүзләре дәлилле, чөнки ул рәсүлебезнең хәдисләренә таянып эш итә. Аның девизы шундый: нинди генә шартларда да кеше булып калу. Ул бу шартларны тулысынча саклый белә. Кеше булып кала белү үз эченә бик күп нәрсәләрне сыйдыра. Аллаһ кушканча яшәү, миһербанлы, ярдәмчел булу, кешеләрне кеше итеп тану, шәфкать итү кебек күренекле сыйфатларны эченә ала. Безнең имамыбызга андый сыйфатлар тумыштан бирелгәндер, күрәсең. Аның кылган гамәлләре белән сүзләре, фикерләре тәңгәл килә. Кеше язмышы, кичерешләре белән яши белү һәркемгә дә тәтеми, билгеле. Һәр кешенең үз кыйбласы, карашы. Мансур имамның кыйбласы туры, карашы ачык, якты. Ул үзенең гел туры юлдан атлаганын тоемлап, сизеп тора, үз-үзен бәяли белә.

Имам – өч улына тугрылыклы ата, онык-оныкчыкларына үрнәк бабай. Андый бабаң, туганың булу – зур бәхеттер ул. Мин үзем дә Мансур абыйга еш мөрәҗәгать итәм, киңәшәм, ачыклык кертәм. Ул шундый намуслы кеше: кайбер вакытта, әүлия микән әллә ул, дип уйлап куясың. Ул инде синең ни әйтергә теләгәнеңне шундук әйтеп сала, киңәшләре белән җәлеп итә. Мин аның Коръән укыганын тыңлап торам да, ерак бабаларымның, 4–5 буын мулла булып торган бабаларымның тавышларын ишеткәндәй булам. Аның тыныч, ягымлы, аһәңле тавышын ишеткәч, күздән яшь ага, йөрәгеңә рәхәтлек килә, күңелдә тынычлык урнаша. Шунда ук мулла Мөхәммәтхәсән бабам күз алдыма килеп баса. Ул да шулай ягымлы тавыш белән җырлап, сихри итеп Коръән укый иде. Менә бит нәселләр чылбыры ничек тоташа. Ике гасырдан артык бу нәсел динебезне, иманыбызны саклый, гасырлар җебен бәйләп тора. Шушы бабайларыбызның исемнәре белән авылыбызның төрле атамалары исемләнеп йөртелә.

Мөхәммәтхәсән чишмәсе, Ишемзәр басуы, Җәгъфәр чишмәсе, Мәхмүт суы дип йөртелә торган атамалар йөрәккә хуш килеп, әледән-әле борынгы бабаларыбызны искә төшереп торалар. Мансур имам үз бабаларының тарихлары турында бик хәбәрдар, алар хакында күп истәлекләр сөйли ала. Кешегә бераз мөмкинлек кенә бирергә кирәк. Дин – дин инде, дөньявиеңны да онытма, дигән бер хәдисебездә. Мансур абый дин белән бергә тормышын да менә дигән итеп алып бара. Ул бик зур итеп өен дә салып чыкты. Үзенең тырышлыгы белән малайларын да башка чыгарды. Хәзер инде аларның тормыш итүләренә сөенеп-куанып дога кыла, Ходайга шөкер итә, балаларын, оныкларын кешелекле, әдәпле, тыйнак, шәфкатьле булырга өйрәтә.

Минзифа ХӘСӘНОВА.
Питрәч районы Шәле авылы

922 2022

1100 еллык тарих

Тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз ХУҖИН ярдәме белән 1100 ел элек Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителү уңаеннан тарихи язмалар циклын дәвам итәбез. Болгар шәһәрләрендә озак еллар казу эшләрен алып барган, ислам дине тарихын өйрәнүгә зур көч куйган галимгә шушы уңайдан сорауларыгызны да җиткерә аласыз.

Тантана

Багдад илчелеге маршрутын һәм Ибн Фадлан язмаларын җентекләп өйрәнү 922 елның 21 маенда узган тантаналарның кайда узуын ачык күрсәтә. Ул Итилдән бер фәрсах (6 чакрым) ераклыкта, Болгар дәүләтенең соңрак шәһәр һәм башкала статусын алган артык зур булмаган бер җирлегендә уза.

Багдадтан килгән илчеләр дүрт көн буена үзләренең чатырларында калалар, илнең башка төбәкләреннән бәкләр, олы бәйрәмгә чакырулы затлар килеп җиткәнче ял итәләр. Пәнҗешәмбе көнне барысы да Багдад хәлифәсенең хатын уку һәм бүләкләр тапшыру тантанасына җыелалар. Тантаналар турында илчелек сәркатибе Әхмәд ибн-Фадлан менә ничек язып калдыра:

«Пәнҗешәмбе килеп җиткәч һәм халык җыелгач, без үзебез белән алган ике чигелгән байракны җәеп җибәрдек, Болгар патшасына җибәрелгән ияр белән атны иярләдек, Болгар патшасын кара киемнәргә киендердек һәм башына чалма кидердек. Мин хәлифәнең хатын чыгардым һәм аңа: «Хат укыганда утырып тору рөхсәт ителми», – дидем. Һәм ул аякларына торып басты, үз дәүләтенең шунда булган күренекле кешеләре дә торып бастылар. Мин укый башладым һәм хатның башын укыдым, һәм «Сиңа тынычлык булсын! Һәм чыннан да, мин сиңа мөрәҗәгать итеп, Аллаһыны данлыйм, Аннан башка бүтән бөек көч юк» дигән сүзләргә җиткәч, мин: «Мөселманнарның хөкемдарына тынычлык теләп җавап бир!» – дидем. Һәм ул җавап бирде, һәм шунда булган кешеләр дә барысы бергәләп җавап бирделәр.

Безнең укыганны хәрефен хәрефкә тәрҗемә итүдә тәрҗемәче дә ялгышмады. Һәм без хатны укып бетергәч, алар «Аллаһу әкбәр!» сүзен әйттеләр. Җир яңгырап торды.

Аннан соң мин вәзир Хәмид ибн әл-Габбасның хатын укыдым, һәм Болгар патшасы бу вакытта басып торды. Аннан соң мин аңа утырырга куштым, һәм ул Нәзир әл-Хәрәминең хатын укыганда утырып торды. Һәм мин хат укуны тәмамлагач, Болгар патшасының иярченнәре аңа бик күп дирһәмнәр чәчтеләр. Аннан соң мин хуш исле нәрсәләрдән, аның өчен һәм аның хатыны өчен булган киемнәрдән, энҗеләрдән торган бүләкләрне чыгардым… Аннан соң мин аның хатынын кешеләр барында бүләкләдем, ә ул аның (Болгар патшасы) белән янәшә утыра иде. Һәм бу – аларның йоласы. Һәм мин аны бүләкләгәндә хатын-кызлар аңа дирһәмнәр чәчтеләр».

Кич белән Багдадтан килгән мәртәбәле кунаклар хөрмәтенә тантаналы аш үткәрелә.

Шулай итеп, Багдад хәлифәсе илчелеге программасының мөһим өлеше – Болгар дәүләтендә рәсми дин буларак исламны канунлаштыру тәмамлана. Болгар иле урта гасыр ислам цивилизациясенең иң төньякта урнашкан өлкәсе булып таныла.

Күпмедер вакыт делегация әгъзаларын ил һәм аның табигате белән таныштыруга, болгарларның яшәү рәвешен, аларның шөгыльләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен, салым салу системасын, мирас кагыйдәләрен өйрәнүгә китә.

Шунысы игътибарга лаек: Багдадка әйләнеп кайткач язылган «Рисалә»сендә ибн-Фадлан үзенең бары тик бер гаиләне генә исламга күндерүе турында хәбәр итә. Биш мең кешедән торган бәрәнҗәрләр кабиләсенә караган кешеләрнең барысы да күптән инде мөселманлыкка күчеп беткән булалар. Аларның агач бүрәнәләрдән салынган мәчетен гарәп илчесе үз күзләре белән күрә.

Илчелек сәркатибе һәм аның иярченнәре мәзиннәргә һәм имамнарга исламның кайбер нигезләмәләренә, Коръән укуда һәм җәй көне намазда килеп чыккан бәхәсле мизгелләргә аңлатма бирергә дә вакыт таба.

Ибн Фадлан китабында Болгар ханы белән ике арада килеп чыккан бер сөйләшү турында яза. Эш шунда: мәзин мәчет манарасыннан намазга чакырып әйтелә торган сүзләрне, икаманы, Багдад шәфигыйләре кебек бер мәртәбә генә түгел, Урта Азиядә кабул ителгән хәнәфиләр мәзһәбе таләпләренә туры китереп, ике мәртәбә әйтә. Бәхәсләр булып ала, әмма сорау җавапсыз кала. Дөресрәге, болгарлар икаманы үзләренчә әйтүдән баш тартмыйлар. Җәйге сезонда намазларның саны турындагы мәсьәлә дә хәл ителмәгән килеш кала, бу исә, Болгар мөселманнары фикеренчә, соңгы төнге һәм иртәнге намазларны берләштерергә мөмкинлек бирә. Шунысы кызык: болгарлар һәм аларның нәселләре, Идел буе татарлары озак вакытлар намазны көнгә дүрт тапкыр укыйлар. Биш тапкыр намазларның мәҗбүрилеге XVIII гасырда гына торгызыла.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

СОЛТАН БУЛЫЙМ ДИСӘҢ...

Мин аны мәктәп елларыннан ук беләм. Сарман районы Иске Кәшер авылы «Ислам нуры» мәчетенең имам-хатыйбы Равил хәзрәт яхшы укыды, җәмәгать эшләрендә дә теләп катнаша иде. Тавышы көчле, матур җырлый, гармун да тарта, спектакльләрдә дә уйнады. Мәктәпне тәмамлагач, хәрби училищега бару иде теләге, нигәдер электриклыкка укырга китте. Анда да, монда да җанына урын тапмагач, ике кызы белән Илексаз мәчетенә йөреп, догалар өйрәнде дә хаҗ сәфәренә китеп барды. Хаҗдан кайтуга, аны мәчеткә имам итеп куйдылар.

Авыл халкы аны башта кабул итмәде. Әзмәвердәй япь-яшь ир-ат, җитмәсә, үзебезнең авылныкы. Җиде буын бабаңның кайда, ни эшләп йөргәнен, ни ашаган, ни эчкәнен беләләр үз авылында. Шунлыктан, солтан булыйм дисәң, башта олтан булырга туры килә икән ул.

Кайчандыр тирә-якта дан тоткан Базарлы Кәшердә өч мәчет һәм… бик зур кабак (сыраханә) булган. Хәзер дә өч урамда өч кибет гөрләп эшләп тора. Менә шул авылны дин юлына бастыруның авырлыгын үз башыннан үткән кеше генә аңлый. Тик иманы нык булды Равил хәзрәтнең, кыйбласын югалтмады. Әнисе Мәйсәрә апа мулла кызы булса, әтисе Шамил абый авылның балта остасы, мич чыгаручысы иде. Әле безгә алмагачлар да ялгап биргән иде. Бер агачта әллә ничә төрле алма үсте. Равил хәзрәт тә аннан калышмый. Кулы эшкә ятып тора. Тәрәзә йөзлекләре, ишекләр ясый. Әтисенә ияреп йөреп, ничәмә-ничә йорт салгандыр ул. Мәчеткә дә матур утыргычлар, мөнбәр ясап куйды.

Мәчет манарасының буявы кубып беткән калайларын алыштырды, яшел утлар куйдырды. Әллә кайлардан балкып күренеп тора. Аерылып төшкән кәрнизне ремонтлады. Бүлмә стеналары буйлап су агып, кошлар пычратып бетергән бүлмәләрне берләштереп, чистартып, уку бүлмәсе ясады. Җил уйнап торган тәрәзәләр (манара тәрәзәләре дә) пластик белән алыштырылды. Мәчет суык булгач, башта электр җылыткычлары куеп карадылар, алай да булмагач, су радиаторларын алыштырып, газ белән җылытуга күчерделәр. Җимерелеп беткән баскыч төбен яңартып, аңа түбә дә куелды. Нигезне тышкы яктан җылытканда, Яңа Имән авылыннан Рафаэль Сәгыйтов бик зур ярдәм итте. Җаны-тәне белән тырышып, булсын дип йөргәнен күреп, авыл халкы да ярдәмгә килде. Шәхси эшмәкәрләр Флер Маликов, аның улы Роберт – мәчеткә иң күп ярдәм күрсәтүчеләр. Әлфирә Мортазина, Раушания Шәймәрданова, Зөлфия Атаҗанова һәм башкалар даими рәвештә матди ярдәм күрсәтәләр. Экскаватор, сварщик, башка техника кирәк булганда, авыл советы рәисе Раян Назыйф улы һәрчак ярдәмгә килә. Боларның бит һәркайсына да барып, баш ияргә кирәк. Сорап бару – бирү түгел, бик авыр эш. Бүген Диния нәзарәтенең шәһадәтнамәсе (указы) нигезендә хаҗи Равил хәзрәт имам-хатыйп вазыйфаларын башкара.

Хәзрәтебез Чаллыдан мөгаллимә чакыртып, дәресләр дә оештырды. Мөгаллимәне автобустан каршы алды, озатып куйды. Ахырда аның гаиләсе һәм туганнары бөтенләйгә күченеп тә кайтты. Унлап хатын-кыз, 4–5 ир-ат җыелды. Әлхәмдүлилләһи, шөкер, өч ел эчендә гарәп хәрефләрен, тәҗвид кагыйдәләрен, гакыйдәне өйрәнеп чыктык. Мөгаллимәбез Фәридә Шәрифуллинаның сеңлесе Зөһрә ханым да, Әлмәттән кайтып, дәресләр бирде. Уку бүлмәсенә заманча карандашлар белән языла торган такта урнаштырдылар, өстәлләр алып кайттылар. Барыбызга да дәреслекләр тараттылар. Намаз укый торган бүлмәне пәрдә белән аерып, хатын-кызларга да укырга мөмкинлек тудырылды. Су кертеп, канализация үткәреп, тәһарәт алу бүлмәсе дә булдырылды. Тәрәзәләргә матур пәрдәләр эленде. Мәчетебездән кайтып китәсе дә килми. Анда җанга нindидер тынычлык, рәхәтлек иңә.

Равил хәзрәтнең хәтере яхшы, догаларны бик тиз ятлый, көн саен яңадан-яңа сүрәләр укый. Башта үзенең гаиләсен, туганнарын ислам юлына кайтарды. Мәчеткә әкренләп картлар гына түгел, яшьләр дә килә башлады. Алар барысы да азан әйтергә өйрәнде, намазга басты. Равил хәзрәт җомга вәгазьләрен шундый мавыктыргыч итеп сөйли, гомере буе укытучы булып эшләгән диярсең. Ул эшли башлагач, зиратлар да тәртипкә керә. Капкаларына язулар эленде. Бу эшләр авылдашларның хәйрия акчаларына, эшмәкәрләр ярдәменә таянып башкарылды. Хәзрәткә һәрдаим булышып, ярдәмгә атлыгып торучылар да бар, эшләгәннәре Аллаһ ризалыгы өчен булсын.

Дини бәйрәмнәрне дә онытмый хәзрәт. Мәүлид кичәсендә пәйгамбәребезнең тормыш юлы, хәдисләре турында чыгышлар тыңлыйбыз. Рәгаиб кичәсендә бик күп төрле салаватларны укыйбыз. Хәзрәт аны һәркайсыбызга бүлеп бирә. Укып, тәфсирен өйрәнеп, башкаларга да сөйлибез. Ураза вакытында авыл советы, эшмәкәрләр ярдәме белән ифтар ашлары, Корбан бәйрәмендә Коръән мәҗлесләре үткәрелә. Бәйрәмгә килә алмаучыларның өйләренә дә күчтәнәчләр җибәрелә. Хәзрәтебез шәхси эшмәкәр дә әле. Ат итеннән хәләл казылык, ысланган итләр ясый. Бәйрәмнәрдә безне дә сыйлый. Гает, җеназа намазларына да кеше күп йөри башлады. Мәчеттә газ плитәсе, кайнар су, табак-савытлар бар. Көндез мәчет ачык тора. Юлчылар кереп, намаз укып, чәйләр эчеп, ял итеп китә алалар. Яшьләребез мәчетне җыештырырга, ашлар әзерләшергә ярдәм итеп торалар.

Мәчетебез манарасыннан иңгән иман нурларына күмелеп йокларга ятабыз, моңлы азан тавышыннан сөенеп уянабыз. Равил хәзрәткә Аллаһның рәхмәте яусын. Барлык авылдашлар исеменнән аңа исәнлек-саулык, бәрәкәтле озын гомер телибез.

Гөлгенә ХӘБИБУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Исәпләү системалары фәнни-җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бүлек башлыгы **Зайченко** Денис Владимирович Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык намуслы хезмәте өчен хезмәт ветераны **Фәйзуллин** Әнвәр Шакир улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың сайлау системасын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары **Скворцяков** Олег Васильевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен композитор, «Россия Композиторлар берлеге» бөтенроссия иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, «Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Кәлимуллин** Рәшит Фәһим улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүләре өчен Бөек Ватан сугышында катнашучы **Әхмәтшин** Җәүдәт Хәсән улы, тыл хезмәтчәне **Гатауллина** Фәрхиҗамал Шәйдулла кызы, тыл хезмәтчәне **Идиятуллов** Абдуллаҗан Айниятулла улы, тыл хезмәтчәне **Нәдершина** Мәрьям Хуҗи кызы; тыл хезмәтчәне **Айдарская** Әлфия Газиз кызы; Бөек Ватан сугышында катнашучы **Гатауллин** Хаҗи Миннәхмәт улы; тыл хезмәтчәне **Кадыйрова** Луиза Шәфит кызы; Бөек Ватан сугышында катнашучы **Кильганов** Петр Фёдорович; Бөек Ватан сугышында катнашучы **Комлев** Алексей Николаевич; «Бөек Ватан сугышы ветераннары – камалыштагы герой-шәһәр Ленинградта яшәүчеләр» Казан шәһәренең җирле иҗтимагый оешмасы рәисе **Комяков** Альберт Павлович; Бөек Ватан сугышында катнашучы **Мәхмүтов** Риаз Мәхмүт улы; тыл хезмәтчәне **Михайлова** Елизавета Григорьевна; тыл хезмәтчәне **Слатинская** Рәйха Идиятулла кызы; инвалидлар – фашизмның элеккеге балигъ булмаган тоткыннары Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмасы рәисе **Хөсәенова** Зәйтүнә Борһан кызы; яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүе һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы мөдире **Александров** Александр Александрович; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Спас муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы Советы рәисе **Бурумова** Татьяна Николаевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Эчке эшләр органнарында намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту бүлегенең оешкан җинаятьчел төркемнәр тарафыннан кылынган наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне ачыклау бүлекчәсе өлкән оперуполномоченные, полиция майоры **Богданов** Илгиз Илдар улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм җирле үзидарәне органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башлыгы **Бурдин** Виктор Михайлович; республикада спортның авиация төрләрен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүдәге казанышлары өчен «Россия армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыятенең (ДОСААФ) Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубы» өстәмә һөнәри белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы башлыгы **Зәйнетдинов** Ринат Рәфгать улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек буенча әйдәүче киңәшчесе – матбугат секретаре **Мөхәммәтова** Алсу Давис кызы; халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең психотерапия һәм наркология кафедрасы профессоры **Нәбиуллина** Римма Рафаэль кызы; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсе профилактика ярдәме һәм сәламәтлекне ныгыту бүлеге башлыгы **Хафизова** Елена Давидовна; мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Түбән Кама шәһәренең концерт-иҗат үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең сәнгать җитәкчесе, халык уен кораллары оркестры дирижеры **Плетнева** Зинаида Ивановна; «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең баш рәссамы **Скоморохов** Сергей Геннадьевич; республикада экологик куркынычсызлыкны һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы **Фәсхетдинов** Марат Гайса улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе башлыгы урынбасары **Ратников** Константин Анатольевичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Шәхси эшмәкәр Гәрәева Фәния Хәйбулла кызының ир-атлар залы парикмахеры **Борисова** Лариса Викторовнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Аңлап булмый...

Адәм баласы – баш-аягы белән кызык зат. Бернинди үлчәм белән дә үлчәп булмый аны, кылган гамәлләрен, уйлаган уйларын, кичергән хисләрен берничек тә аңлатып булмый. Үлчиләр инде ул үлчәвен, әллә ниләр кыландырып бетерәләр. Авырлыгын, буен, билен… Бар яклап та бизмәнгә салып карыйлар. Акылын да, тәртибен дә, сөйләшү рәвешен дә, саранлык-юмартлыгын да тикшерәләр. Ә гайбәтчеләр теленә эләксәң, ата-бабаңнан башлап бөтен күзәнәкләреңне бөртекләп барлап чыгалар. Тик барыбер кешене аңлап бетерә алмыйлар. Ләкин үзеңнең аңлый алмавың белән килешеп булмый. Шуңа күрә теге кешене ахмак я юньсез дип бәялиләр. Бәлки, чынлап та шулайдыр. Менә мин инде гомер буе диярлек күзәтәм: бу дөньяда бер акыллы, бер юньле кеше юк бугай, бары тик кайберләренең ахмаклыгы артык зур һәм артык якында була, ә зур ахмаклык ул ерактан гына күренә. Якыннан караганда аның нәрсә икәнен дә аңлый алмыйсың.

Менә безнең авылда бер абзый бар иде. Салырга ярата инде бу. Исергән чагында килде-китте сүз сөйләп, бәйләнеп, кеше нервысына тиеп йөрми үзе. Ихлас итеп аралаша, кирәк булса, ярдәмләшә дә. Анысы да берәр эрүмкә өмет итүдән түгел, чын күңелдән. Якты кеше инде, кыскасы. Ләкин яктылыгыннан һәрвакыт аракы исе аңкып тора. Шуңа күрә авылдашлар моңа көлебрәк, түбәнсетебрәк карыйлар. «Тагын салган инде, мәңге туя белмәде», – диләр. Кәефләнеп алган чакларында үзе дә яшереп тормый:

Уңнарын унга салам,
Сулларын сулга салам.
Зарымны суга салалмыйм,
Җан яна, шуңа салам, –

дип җырлап җибәрә. Тавышы да, моңы да бар, җыры шундук бугазга төер утырта. Хатыны, балалары авариядә үлгән аның, җаны ник янганы беркемгә дә сер түгел. Тик барыбер кызганучы сирәк инде, күбесенчә беткән бер бәндәгә исәплиләр. Менә шул абзый акчага бик интеккән чагында абзарындагы үгезләренең берсен ярты хакына сатып җибәргән. Җибәргән дип, бер-ике өй аша торган күршесе сатып алган инде. Миңа калса, кешеләр шул күршесен гаепләргә тиештер кебек. Ну, мохтаҗлыкка төшкән кешенең малын шул бәягә алу дөрес түгел бит инде. Мыскыл итү кебегрәк бит инде бу. Ләкин авыл халкы башкачарак уйлады бугай. Бу абзыйдан көлделәр. Дивана диделәр. Күз дә ачырмадылар. Аек чагында берәр җитди урында сүз әйтергә теләсә дә: «Үгезен фәлән сумга саткан бәндәнең сүзен тыңлап, гомер кыскартасы эшебез юк», – дип авызын томаладылар. «Дивана» келәймәсен йөртү акыллы кешеләргә дә бик җиңел түгел инде ул…

Ул абзыйны мин бераз хөрмәт иткәнмендер инде, гел искә төшерәм. Сәбәпләре дә күп бугай. Нәрсәнеңдер символы шикеллерәк тә ул. Пирамидалар оештырган кешеләр, халыкны акчасыз калдырган банклар күп булды бит инде. Менә шунда алданган халык та «дивана» булып калды. Ә аларның хәләл акчасын тартып алган явызларга берни дә булмады. Кайберләре хәзер бик абруйлы кеше булып йөри. Әллә бу халык үзен алдаган, откан, талаган бәндәләрне ныграк хөрмәт итә ул? Кумир итеп күрә… Ә бәлки эчтән генә: «Их, берәр кайчан мин дә шулар кебек булсам иде», – дип хыялланучылар да бардыр әле. Кешене берничек тә аңлап я бәяләп булмый. Халыкны бигрәк тә.

Дөньясы да абзыйны онытмаска тырышкан кебек аның. Бер мәлне авылдагы хуҗалык рәисләре җыелган ашлыкны арзан бәягә генә каядыр тапшырып кайталар да: «Быел фәлән тонна ашлык үстереп саттык!» – дип мактана торганнар иде. Үзләренә берәр төрле файдасы булгандыр инде аның. Югыйсә авыл халкына шул бәягә бирсәләр дә, сөенә-сөенә алып бетерерләр иде. Ә монда читкә, ярты бәясенә… Үгезен сатып җибәргән теге абзый кебек бит инде. Ләкин рәисләрне «дивана» диюче булмады. Әле дә… Фәлән илгә фәлән кадәр нефть саттык, фәлән күләмдә – газ, дигән шатлыклы авазлар ишетелгәли. Халык сөенә. Сатып алучылар да сөенә ди. Алган товарларын әвеш-тәвеш китереп яңа рәвешкә кертәләр дә фәлән хакка сатып җибәрәләр икән. Бөтен дөнья шатлана. Берәүне дә «дивана» диюче юк…

Дивана дигәннән… Тагы бер абзый искә төште әле… Бәләкәй чак, иптәш малайның ишегалдында атышлы уйныйбыз. Немецләр белән безнекеләр инде. Элек шулай иде бит. Ихата бәләкәйрәк булгач, ерактан атышып кына булмый, кул сугышына керешеп китәбез, көрәшәбез, көрмәкләшәбез. Бер мәлне күрше карты килеп керде дә «немес»ләрне кыйный башлады. Мин «безнекеләр» ягында идем, башта сөендем инде аның ярдәм итүенә. Соңрак күз маңгайга менде. Теге бабай чынлап кыйный иде. «Әле син дөмекмәдеңме, фашист?!» – дип, таягы белән тондыра. Кая сукканын да карап тормый, манчый гына. Ярый әле иптәш малай елап җибәргәч, әнисе чыкты. Картны тирги теге. Урамнан силсәүит персидәтеле узып барган чак булган, тавышка ул керде. Хәлне аңлагач, бабайны тирги генә башлаган иде, тегесе таягы белән җиргә бер генә орды да: «Әле син фашистларны яклап торасыңмы? Белермен мин кемгә әйтергә…» – дип кенә куйды. Персидәтел шундук телсез калды. Һушына килгәч: «Атышлы уйнамагыз. Бүтән уеннар да бетмәгән, барыгыз, яланга чыгып туп тибегез», – дип безне куарга тотынды. Хәтта теге малайның әнисе дә улын тиргәргә кереште. Ә бабай Берлинны алган сыман горур кыяфәттә чыгып китте. Озак кына куркып йөрдек аннан. Ул бөтен нәрсәне дә беләдер, бөтен кешене дә җиңәдер, ни теләсә, шуңа ирешәдер кебек иде. Хәзер юк инде, үлде. Берәү дә мәңгелек түгел. Буй җитмәслек булып тоелса да. Иң кызыгы шул әле аның: үзе исән чакта беркем берни сөйләмәде, курку катыш хөрмәт күрсәттеләр, ә җирләгәч: «Дивана иде бит ул, хәтта сары справкасы бар иде», – диделәр. Кайбер кешеләрнең дивана икәнлеге дә үзләре үлгәч кенә ачыклана. Әйтәм ич, зур нәрсәләрне күрү өчен ераклык кирәк.

Кеше – ачылмаган сер. Аны бернинди үлчәмнәр белән дә тулысынча бәяләп тә, аңлап та булмый. Һәрберебез шундый. Шикле нәрсәләрдән ерак торыйк. Хәер… Шикле нәрсәләрдән ераклашсаң, үзең дә шикле булып күренәсеңдер әле ул…

Диплом № 111624 3238367 от 01.07.2019 г., регистрационный номер 917, выданный ГАПОУ «Казанский энергетический колледж» на имя Лукина Вячеслава Юрьевича, в связи с утерей считать недействительным.

Газетаның киләсе саны 13 майда чыга

НАИЛ ШӘРИФУЛЛИН: «ДӨНЬЯГА ҖИТКЕРӘСЕ СҮЗЕМ БАР»

Безнекеләр

«Ватаным Татарстан» газетасында инде күп еллар «Җиденче каттан караш» рубрикасын (аңа кадәр «Фикер» дип атала иде) алып баручы хезмәттәшебезнең болай дип әйтергә, һичшиксез, тулы хакы бар. Ул һәр атна дөньяда, Россиядә барган сәяси хәлләр, аларның республикабызга йогынтысы турында бәйнә-бәйнә укучыларыбызга аңлата, ягъни мәсәлән, төпле анализ ясый.

Хезмәттәшебезне юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз! Исәнлектә, иминлектә яшәргә язсын, язмалары белән газетабызны баетып, укучыларыбызны куандырып торсын дигән теләктә калабыз.

Бервакыт шулай үзара сөйләшеп утырганда, Наил: «Язучы, публицист халыкка сүзен җиткерерлек итеп 50 яшьләр тирәсенә генә өлгереп җитә, аңа кадәр ул җим җыя әле», – дигәнрәк фикер әйткән иде. 7 май көнне ул үзе алты дистәне тутыра, димәк, өлгерү генә түгел, пешеп җиткән дигән сүз инде бу. Шуңа күрә аның һәр язмасы мантыйкка нигезләнеп язылган, саллы фикерләргә бай. Укучыларыбыз гына түгел, редакция хезмәткәрләре дә көтеп ала, яратып укыйбыз.

Хезмәттәшебез – искиткеч үзенчәлекле кеше, дип язсам, мөгаен, ялгышмамдыр. Иң гаҗәпләндергәне – мөгаен, аның инде чагыштырмача өлкән яшьтә башы белән кереп чумган техника өлкәсеннән язу-сызу эшенә күчүедер. Кайчан да булса газетада, бигрәк тә «Ватаным Татарстан»да эшләрмен дип башына да китереп карамый ул. Баулы районының Исергәп авылында туып үскән егет Казан авиация институтына юл тота. Радиоэлектроника факультетын тәмамлап, Лениногорскидагы хәрби заводта эшли башлый. Барысы да гадәттәгечә кебек: самолетларга электрон җиһазлар җитештерү цехлары, лабораторияләр, конструкторлык бюролары…

Бервакыт шулай заказлар булмау сәбәпле, хәрби предприятиеләр бер-бер артлы банкротлыкка чыга башлый. Наил дә җиде юл чатында кала. Нефтьчеләр янына килеп чыга. Буш вакытларда үзе өчен генә хикәяләр языштыра башлый, газеталарга язмалар әзерли. Ул хәзер бу гамәлләрен инженер булып эшләгәндә дөрләп янган иҗади эшенең дәвамы, ахры, дип фаразлый.

«Ватаным Татарстан»га килеп эләгүен, бер караганда, очраклылык дип бәяләргә дә мөмкин булыр иде. Монысын үзе дә Лениногорскидан килеп, республика газеталарында эшли башлаган Илфак Шиһапов белән бәйли ул:

– …Нефтьчеләр янында эшләп йөрим. Эш белән Казанга килеп чыккан чакларда редакцияләргә сугылам. 2005 елның көзе. Ул көнне мин үзем белән «Казан утлары»на дип бер зур булмаган хикәя, «Татарстан яшьләре»нә тәгаенләп, мәкалә алган идем. Лифтта кеше күп иде.10 катка менәм дип ниятләсәм дә, башкалар артыннан чыгып, ялгыш 7дә төшеп калганмын. Калган юлны җәяү генә менәргә булдым. Баскыч мәйданчыгына чыксам, ни күрим: Илфак Шиһапов, үз төтененә үзе үк гаҗизләнеп, күзләрен кысып, тәмәке тартып тора. Сөйләшеп киттек, бүлмәсенә чакырды. Ярты сәгать аралашуның нәтиҗәсе шул булды: «Татарстан яшьләре»нә әзерләнгән язмам «Ватаным Татарстан»да калды. Бер атнадан «толстушка»да бер бит булып дөнья да күрде. Башка язмаларым да чыга башлады. Ул көнне этажларны бутауны очраклылык дип атыйсым килми. Ул гынамы, бүген мин авыз тутырып, газетабыз ишеген миңа беренче тапкыр киң итеп киереп Илфак ачты, дип әйтә алам.

Илфак күрсәткән юл уңышлы була. Берничә елдан Наил Казанга килә дә, мөхәррир янына кереп, кыяр-кыймас кына сүз башлый, штатлы хезмәткәр булырга теләвен җиткерә. Мөхәррир авызыннан «сөендердең әле син безне» дигән сүз чыккач, ышанырга да, ышанмаска да белми ул. Әмма очар өчен канатлар куела. Монысы хак.

– Язганнарым ихлас дию генә аз. Алар – минем дөньяга, җәмгыятькә карашым, илдәге бүгенге вазгыятькә, сәяси вакыйгаларга үз бәяләмәм, алай гына да түгел, алар – минем инануларым. Инануларыңны халыкка ирештерер, менеп сөйләр өчен затлы, тарихлы мөнбәрең булу ул – үзе бәхет, – ди хезмәттәшебез бу җәһәттән.

Наил Шәрифуллин укучыларыбызга язучы буларак та яхшы таныш. Үрнәк алырлык якын кешесе дә бар аның: Миргазиян Юныс белән авылдашлар.

– Миргазиян абыйның китапларын укып үстем. Татар язучысы дип аталыр өчен аның кебек татар дөньясын шаулатып алган әсәр язу кирәктер ул. Язучы ул – олы исем. Каләм тибрәткән һәр кешене бу исем белән атау тыйнаксызлык булыр иде. Мин үземне андый шөгыльсез тора алмаучылар сафында дип уйлыйм, – дип үзенә тыйнак кына бәя бирә Наил. Әмма, иманым камил, аның китапларын кулына алган кеше башкача уйлар иде.

Миргазиян абыйсы диңгез киңлекләрен сагынган кебек, ул да, үзе әйтмешли, очучы булмаса да, авиация дөньясын сагына. Хезмәттәшебез кайчандыр хәрби очкычларны «акыллы» итә торган электрон җиһазлар җитештерү өлкәсендә хезмәт куя. Армия хезмәтен космик гаскәрләр сафында уза. Экипажсыз ясалма иярченнәр белән идарә итә. Офицер тормышы үзе бер мәктәп була аның өчен.

– Электроника – үзе бер гаҗәеп зур, серле дөнья, – ди Наил. – Виртуаль, эчеасылы күзгә күренми, бары приборлар, экранга чыккан символлар аша гына барлыгын тоеп була торган параллель җиһан ул. Үзем уйлап тапкан, автосөючеләргә тәгаенләнгән бер җиһаз, сериягә кертелеп, шактый еллар җитештерелеп тә килде. Заводлар таркалмаса, мин, бәлки, электроникадан аерылмаган да булыр идем…

Кем белә, бәлки, монысы да очраклылык түгелдер. «Ташка басылган» язмалары аша халык аның сүзләренә колак салырга тиештер, күрәсең. Бигрәк тә татар матбугатында сәясәткә йөз тоткан аналитик калыптагы мәкаләләр язучы журналистлар бик сирәк. Димәк, Наил Шәрифуллин дигән публицист безгә бик тә кирәк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЭШЛӘРГӘ КИРӘК БИТ ИНДЕ...

Менә шундый кеше

«Ленар килгән икән!» Балтач кешеләре аны әнә шулай каршы ала. Атнаның өч көнендә район үзәгендәге ачык базарга язын-көзен махсус эзләп килүчеләр дә күп үзен. Әллә кайчан үз кешегә әйләнгән инде ул. «Ни дисәң дә, егерме елдан артык киләм бит», – ди Ленар.

Әнә шул егерме елда ул саткан чәчәк-гөлләрне, агач-куакларны, үсентеләрне бергә җыйсаң, берничә зур плантация хасил булыр иде… Чөнки машина-машина үсентеләр төяп килә, бөтенесен диярлек сатып бетереп китә. Күз явын алырлык чәчәк-гөлләре белән әллә каян сатып алучыларны кызыктыра да, тәмле теле белән беркемне дә буш җибәрми ул.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы икән Ленар. КФУ тәмамлаган. Тик мәктәптә бер генә ел эшләгән. Китүенең сәбәбен болай аңлата:

– Мин студент чакта ук эшмәкәр идем инде. Беренче елларда базарга барып, чәчәк, җимеш агачлары-куаклар сатучыларны күзәтергә ярата идем, бу миңа бик ошый иде. Ә югары курсларда инде үзем дә розалар, аз-азлап булса да куак-агачлар сата башладым.

Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылы егете ул. Үзе шунда ук, Президент авылыннан мин, дип тә өстәп куя.

– Ни өчен нәкъ менә бу юнәлешне сайладың? – дим.

– Бетә торган эш түгел бу, мәңгелек бизнес. Шуңа, һич икеләнмичә, мөмкинлек чыгу белән үз эшемне булдырдым. Без илле сутыйлы участокта яшибез. Шунда барысы да сыйган: биш сутыйлы чәчәк теплицасы һәм питомник та бар. Әмма барысын да үзең генә үстереп бетереп булмый, Удмуртиядәге, Мичуринскидагы питомниклар белән дә эшлим.

– Ничә карасаң, синең янда кеше күп була, чәчәк сезонында бөтенләй камап алалар. Ә син бертуктамый сөйлисең, бөтенесен һәр кешегә әйбәтләп аңлатасың…

– Менә шуңа күрә яраталар да инде мине. Әйтик, менә хәзерге чорда кешеләрне агач-куаклар, үсентеләрне нәрсә белән, ничек эшкәртергә дигән сораулар борчый. Мин аңлатам да, препаратын да бирәм. Бер алган кеше, инде белеп, кабат шуны сорый. Кешене бер генә тапкыр алдап була, кабат ул синең янга килми. Тагын мине агачларның сортлары сортына туры килгәнгә яраталар дип беләм. «Ленар, синнән груша, алмагач алган идек, шундый күп итеп җимеш бирде», – дип тә әйтәләр. Мондый сүзләрне ишетү бик рәхәт…

Унбер район белән эшли Ленар Әхтәмов. Балтач, Саба, Кукмара, Теләче, Питрәч… – иң ерагы Буа. Үзләрендә питомник булса да, Буада да мине көтеп торучылар, миннән алучылар шактый, ди ул. Чәчәкләр-гөлләр, җимеш агачлары, куаклар (декоративларны да) күпләп үстерсә-сатса да, Ленар үзен танылган суган сатучы дип тә саный. «Күп еллардан бирле Нидерландтан кайтарып, 5–6 тонна, элегрәк әле унар тонна да була иде, орлыклык суган сатам. Уңышы да әйбәт була, авыруларга да бирешми дип яратып алалар», – ди.

Әле бу да Әхтәмовлар бизнесының икенче юнәлеше генә. Тагын аларның азык-төлек, машина запас частьлары кибетләре һәм шиномонтажлары бар.

– Сигез кешене эшле итсәк тә, гаилә бизнесы бу безнең, – дип дәвам итә Ленар. – Тормыш иптәшем Рузалия белеме буенча элемтәче булса да, барлык исәп-хисап эшләрен, документларны алып бара. Балалар да аның өстендә булды. Өч улыбыз, бер кызыбыз бар. Барысы да шушы эшләрдә кайнап үстеләр. Олысының Казанда үз бизнесы бар инде, төпчегебезгә ун яшь, ул да бик яратып көн дә теплицада мәш килә, заманча су сиптерү системасы булса да, «эшләргә кирәк бит инде» дип, лейка белән су сибеп йөри.

Сезон вакытында йокы күрмәсәләр дә, гаилә башлыгының күпчелек вакыты тәгәрмәчләр өстендә үтсә дә, ялгышып та зарлану сүзе ишетмәссең Ленардан. Яратып эшләү шушы буладыр инде…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Еланнар туй итәргә уяна

Татарстан тирәлегендә дүрт төрле елан очрый. Бу – тузбаш, бакыр, кара һәм кыр кара еланнары. Аларны кайда очратырга мөмкин? Елан чакса, нишләргә? Чакмасын өчен нинди чаралар күрергә? Белгечләр шул сорауларга җавап бирде.

Идел-Кама тыюлыгы өлкән фәнни хезмәткәре Алексей Павлов сүзләренчә, еланнар кар төшүгә һәм тәүлекнең уртача температурасы +5 градуска җитүгә уяна башлый. Туй итәргә!

– Еланнар, кышын яткан урыннарыннан чыгып, бергә җыела. Шул рәвешле «елан туе» башлана. Ата затлар нәсел дәвам итү һәм ана зат белән парлашу мөмкинлеге өчен ярышырга тотына, – дип аңлатты Алексей Павлов. – Еланнар һава температурасы арткан саен активлаша. Әмма 30 градустан артык эсседә алар кояштан качып, посып утырачак. Алар бу температурада үләргә дә мөмкин.

Былтыр Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсенә елан чаккан 20дән артык кеше мөрәҗәгать иткән булган. Быел әлегә андый мөрәҗәгатьләр белән килүчеләр юк.

– Былтыр 12 кешене кара елан чаккан иде. Үлем-китемнәр булмады. Алар хастаханәдә дәваланып чыкты, – ди Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгече Алия Насыйбуллина.

Еланны республиканың бөтен территориясендә дә очратырга мөмкин анысы. Иң «тешле»ләре исә Лениногорск, Әлмәт, Бөгелмә районнарында икән. Казанга якын районнарда да очрый алар.

– Елан чагу очракларының саны урман күплегенә генә бәйле түгел. Әйтик, урманнары күп булган Нурлат районында елан чагу очраклары аз, чөнки районның халык яши торган өлеше – бер, урманнар икенче якта урнашкан. Яшел Үзәндә исә, халык саны күп булганга, кара еланнар бөтенләй юкка чыкты. Кара елан димәктән, аларны шәһәр паркларында очрату ихтималы кечкенә. Аны сулыклар булган җирдә күрергә мөмкин. Эссе көннәрдә чишмә тирәләренә оялыйлар, – дип аңлатты Алексей Павлов.

Киңәш



✓ Табигатькә чыкканда кием-салым, азык-төлек ягын гына түгел, психологик халәтне дә кайгырту мөһим дип искәртә белгечләр. Еланнар черегән, киселгән агач төбен дә үз итә, үлән астында да оя кора. Шул тирәләрне үткәндә аеруча сак булырга кирәк, димәк. Еланнар иртәнге якта аеруча актив. Көндез һәм кичен исә алар кайнар кояштан качып, ышыкта яталар.

✓ Табигатькә чыкканда, калын өс һәм аяк киеменнән булырга киңәш ителә. Гөмбә, җиләк җыярга барганда, кулга таяк тоту да кирәк.

✓ Елан чакса, яралы урынны һич кенә дә жгут белән кысарга ярамый. Бу хәлне катлауландырырга да мөмкин әле. Елан чаккан мәлдә кул астында гормональ, антигистамин төркемгә караган дарулар, стериль чүпрәк, бинт булса яхшы.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7061 данә
Гомуми тираж – 16033 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 264

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+